ҺӘР ТИЕН ИСӘПТӘ
Бюджет проекты турында финанс министры белән әңгәмә
> 5

БАЗАР ҖИЛЕ
Авыл кешесе заман шартларына яраклаша
> 5

ЯШӘҮЧЕ КАГЫЙДӘЛӘРЕ
Бетү турында түгел, яшәү турында уйлыйлар бу авылда
> 6

САБЫН ЯСАУ ОСТАЛАРЫ:
«Соңгы елларда сабын сатып алганыбыз юк»
> 6

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 145 (28727) | Чәршәмбе | 6 октябрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

БЕР ЙОДРЫККА ТУПЛАНЫР ЧАК
15 ОКТЯБРЬДӘН БӨТЕНРОССИЯ ХАЛЫК САНЫН АЛУ БАШЛАНА

Җанисәп

Соңгы арада телдән төшмәгән җанисәпкә ун көннән азрак вакыт калып бара. 15 октябрьдән 14 ноябрьгә кадәр ил күләмендә халык санын алу узачак. Башка еллардан аермалы буларак, быелгы җанисәп коронавируслы катлаулы шартларда үтә. Шуңа бәйле рәвештә Бөтенроссия халык санын алуда яңалыклар да бар.

Федераль дәүләт статистика хезмәтенең Татарстан буенча территориаль органы (Татарстанстат) җитәкчесе Наталья Гатауллина сүзләренә караганда, Бөтенроссия халык санын алуга әзерлек эшләре тулысынча тәгәлләнгән. Республикада җанисәп үткәрүдә барлыгы 8,5 меңнән артык кеше катнашачак. Башка еллардан аермалы буларак, быел бу эшкә волонтерларны да җәлеп итәчәкләр.

– Халык санын алу өчен 7108 кеше сайланды. Аларның 48,6 проценты – мәгариф хезмәткәрләре, 32,5 проценты – төрле учреждение һәм предприятие хезмәткәрләре, 10 проценты – җирле үзидарә органы вәкилләре, 3 проценты – эшләмәүче пенсионерлар һәм хезмәткә сәләтле булган вакытлыча эшсез кешеләр тәшкил итә, – диде Наталья Гатауллина Хөкүмәт йортында узган брифингта. Халык санын алучының өстендә зәңгәр жилеты, сумкасы, шарфы, үзе белән махсус таныклыгы булачак. Ул халыктан алган мәгълүматны планшет ярдәмендә турыдан-туры базага кертеп барачак. Планшет эшләмәгән очракта ул кәгазь бланктан да файдалана ала.

Яшерен-батырын түгел, арабызда ун елга бер үткәрелүче халык санын алуның асылын әле дә булса аңлап бетермәүчеләр шактый. Өстенә махсус кием кигән таныш булмаган кеше, синең янга килеп, синең кем, кайсы милләттән, нинди яшьтә булуың, кайда торуың, нинди белем шогыльләнүең турында бер-бер артлы сорау яудыра башлагач, ирексездән башта: «Әлеге мәгълүматлар боларга нишләтә һи өчен кирәк икән?» – дигән сорау туа. Бу аңлашыла да. Халыкның әле бер, әле икенче төрле ысуллар белән төп башына утыртулары турында кәнаралаш хәбәрләр ишетеп яшәгән заманда мондый сорау алуларга да үзеннән-үзе шикләнеп карый башлыйсың. Өстәвенә көндәлек тормышта урамнарда, зур сәүдә үзәкләрендә дә шуның ише сораулар белән аптыратучылар даими рәвештә очрап тора.

Шуңа күрә тагын бер кат искәртеп китү артык булмас: җанисәп бернинди сорашыру да, тикшеренү дә түгел. Ул илдә яшәгән халыкның исәбен алудан гыйбарәт. Татарстанның икътисад министры урынбасары Роман Эмирханов белдерүенчә, халык саны турында тулы мәгълүмат бюджет формалаштырганда да кирәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Бу мәгълүмат кайсы районда күпме балалар бакчасы, хастаханә, фельдшер-акушерлык пункты, китапханә, музей, клуб, мәктәп төзергә кирәклеген аңларга ярдәм итә. Шуңа күрә халык санын алуда һәркемнең катнашуы мөһим, – дип белдерде ул журналистлар белән очрашуда.

Алда телгә алынганнардан тыш, җанисәп – үз халкы, милләте, теле белән горурланган һәркем өчен мин менә шул милләттән, минем туган телем әнә шул дип тагын бер кат тәгаенләү, тамырларыңны күрсәтү өчен менә дигән мөмкинлек тә ул! Халык санын алу вакытында кешенең яше, гаилә хәле, белем дәрәҗәсе, милләте, нинди телләр белүе, яшәү урыны, яшәү шартлары, керем чыганагы, кайда эшләве белән бәйле стандарт сораулардан тыш, йөрәк һәм намус кушканча җавап бирелергә тиешле төп ике сорау әнә шуны күздә тота. Син нинди милләттән? Туган телең нинди? Сүз уңаеннан, халык исәбе алуда катнашкан кешеләрнең шәхси мәгълүматлары беркая таратылмый, чәчелми. Анда катнашкан кешедән килочәктә салым түләттерәләр икән дигән имеш-мимешләр дә дөреслеккә туры килми. Халык санын алудан һич кенә дә куркырга кирәкми, кыскасы.

Җиткерәбез, җилдә сынала дигәндәй, җанисәп вакытында да тегә яки бу халыкның, милләтнең ни дәрәҗәдә бердәм, бер йодрык булып туплануы күзгә ташлана. Бердәмлекне сүздә генә түгел, кәгазьдә дә күрсәтә белү мөһим. Үзен керәшен, мишәр, типтәр дип язып алган кешеләр халык санын алу нәтиҗәләре буенча татарларга кертеләчәкме, әллә инде аерым милләт булып исәпләнәчәкме?

Ахыры 2 нче биттә >

2023 ел укытучыларга багышланачак

Россия Президенты Владимир Путин 2023 елны Укытучы һәм остаз елы дип игълан итте. Ул Россиядә фәнни педагогикага нигез салучы Константин Ушинскийның тууына 200 ел тулуга да багышланачак. Якын арада аңа әзерлек эшләре башланачак.

Август аенда бу идеяне Мәскәүнең 1514 нче мәктәбе укучысы тәкъдим иткән иде. Россия Президенты укучының сүзләрен хуплады. Октябрь башында исә ул Укытучы һәм остаз елын үткәрү турында Указ проектын тәкъдим итәргә кушкан иде.

Компьютер теленә өйрәтәләр

Мәктәп укучыларын программалау теленә өйрәтә торган төбәкләр арасында Татарстан да бар. Бушлай курслар 2021 елда башланып китачәк. Алар илнең биш төбәгендә сынау проекты буларак гамәлгә ашырылачак. Бу хакта Россиянең Цифрлы үсеш министрлыгы хәбәр итә.

Барлыгы 2 меңнән артык мәктәп баласын укыту ниятләнә. Әлеге курс математика һәм информатика фәненә өстәмә булып барачак, ул 14 яшьтән өлкәнрәк укучылар өчен. Проект 2022 елның июнь аена кадәр дәвам итәчәк. Курсларның эчтәлеген, вакытын, программасын исә соңрак ата-аналар һәм укытучылар ярдәме белән үзгәртергә дә мөмкиннәр. Курс «Цифрлы икътисад» илкүләм программасының «Цифрлы икътисад өчен кадрлар» федераль проектында каралган чаралар исемлегенә керә.

Ипотека портфеле «кабара»

Татарстан халкы торак шартларын ипотека ярдәмендә яхшырта. Агымдагы елның 8 аенда республикада яшәүчеләр 42 меңнән артык ипотека кредиты алган. Бу, узган елның шушы чоры белән чагыштырганда, 23,5 процентка артыграк. Сан теленә күчерсәк, барлыгы 106 млрд сум. 2021 елның августында ипотека кредиты буенча уртача айлык ставка 7,77 процентны тәшкил иткән.

Шунысын да әйтергә кирәк: кредит алучылар үз бурычларын вакытында түләп бара. Агымдагы елның 1 сентябренә кадәр кичектерелгән бурыч өлеше «ипотека портфеле»нең гомуми күләменең 0,46 процентын гына тәшкил иткән.

Сораштыру

Инстаграмсыз кич

Дүшәмбе киче күпләрне шок кичерергә мәҗбүр иткәндер. Бер мизгелдә барлык популяр социаль челтәрләр (Ватсап, Инстаграм, Фейсбук һ.б.) эшләми башласын әле! Телефон экраның сыпырга күнеккән халык нәрсә белән шөгыльләнде икән? Кинәт кенә барлыкка килгән буш вакытны нәрсәгә багышлаганнар? Социаль челтәрләрдән башка тормыш та бар икән югыйсә. Моннан сабак алганнармы?

Гөлүсә БАТТАЛОВА, шагыйрә (Әтнә):
– Бу хәлне аңлап та бетермәдем. Минә шаксыз әллә ни зыяны булмады. Интернет томый, дип кенә уйладым. Ватсапның эшләмәве генә бераз борчыды. Хезер мәктәп, укытучы белән элемтә дә шуның аша бит инде. Эштәгеләр белән дә шулай. Социаль челтәрләр юкка чыкса, үземә артык зур зыян килер дип уйламыйм. Киресенчә, файдалырак эшләргә, шөгыльләремә вакытым күбрәк калыр иде. Ватсап шикелле аралашу «челтәр»ләре безнең эшне бик купкә җиңеләйтә. Алар бетсә, әлбәттә, кыенрак булыр.

Айваз САДЫЙРОВ, «Тәртип» радиосы продюсеры, «Манзара» тапшыруын алып баручы:
– Минем өчен бу фаҗигагә әйләнмәде. Бу 5–6 сәгатьне сизми дә калдым, чөнки бу вакытта оффлайн тормышта яшәдем: китап укыдым, гаиләм белән булдым. Озак вакытка юкка чыкса, бу миңа бәйле өлкәләргә дә зыян китерәсе иде, әлбәттә. Әммә дөнья күләмендә караганда, бу – чын фаҗига. Бу бер атнага сузылса, ни буласын күз алдына да китерәп булмый.

Ринат ГАЛИӘХМӘТОВ, беренче татар инстаблогеры:
– Без авылда идек. Ватсап, Инстаграм эшләми башлагач, тагын вай-фай көйсезләнәдер инде, дидем. Шулай бер сәгать узды. Интернетка кереп, ни өчен бу социаль челтәрләрнең эшләмәвен белергә баш эшләми генә бит! Имештер, бездә генә шулай. Төнге бердә генә яттым. Ул вакытта Инстаграм эшли башлаган иде инде, куясы нәрсәләрне куйдым. Социаль челтәрләр бетсә, бозаулар алабыз, фермер булам, дип көлештек әле. Бу вакыйгадан соң башыма шундый уй килде: без социаль челтәрләргә бәйле икән. Мин иркенлек сиздем. Ватсап юк, Инстаграм юк, чыгып керим әле, дип урамга чыгасың, рәхәтләнеп мунча кердем.

Рушан САЙРАНОВ, яшь фермер (Кайбыч, Кошман):
– Эш буенча бер кешегә ашыгыч рәвештә хәбәр язып саласым бар иде. Социаль челтәрләрдәге көйсезлекләр миндә генә дип уйлыйм бит әле. Телефонга акча салдым, аннан әллә ничә тапкыр телефонны сүндереп кабыздым. Мин бу хәлдән сабак түгел, тынычлык алдым. Социаль челтәрләр бетүдән генә тормыш туктамый. Бары тик кабер эшләр озакка сузылырга мөмкин. Кешене секунд саен аптыратучы булмый. Биш-ун җирдән шалтырату, хәбәр килми. Ул дәрәҗәдә оперативлык кирәкме соң безгә?

Ренат ГАЛИӘСКӘРОВ, алып баручы:
– Кечкенә чакта ут беткән вакытлар бик еш була иде авылда. Әллә ни сабак алдым, дип әйтә алмыйм… Нәкъ балачакта ут беткән кичләрдәге кебек, бераз хисләнеп утырдым да кичке сигездә ятып йокладым. Шәхсән минем өчен социаль челтәрләр – эш инструменты да, фикеремне халыкка җиткерү ысулы да. Бераз кыенлыклар килеп чыгар иде. Тик адәм заты барысына да тиз яраклаша, берәр нәрсә уйлап табар идек әле!

Теманың дәвамы 2 нче биттә >

Татармын! Горурмын!

Габдулла ТУКАЙ

**Күңел берлән сөям бәхтен татарның,
Күрергә җанлылык вактын татарның.**

**Татар бәхте өчен мин җан атармын:
Татар бит мин, үзем дә чын татармын.**

КЕМГӘ КҮБРӘК ЫШАНАСЫЗ?

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге Россия халкының башкаларга булган ышанычы турында кызыксынган. Сораштыруда катнашучыларның 36 проценты үзен аралашучан дип атаган. 60 проценттан артыгы исә таныш булмаган кешеләргә артык ачылып китәргә әзер түгел икән.

КЕМГӘ НЫГРАК ЫШАНАЛАР?

Иренә яисә хатынына	48%
Балаларына	43%
Әти-әнисенә	39%
Балачак дусларына	20%
Бертуганнарына	20%
Хезмәттәшләренә	18%
Башка туганнарына	16%
Интернеттагы танышларына	2%

Кыргый хайваннарга бәреләләр

Пошп, кабан, кыр кәҗәсе – республика юлларында машина астында калучы хайваннар исемлегендә әнә шушы кыргый хайваннар бар. Соңгы арада мондый очраклар арткан, дип кисәтә Татарстанның биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты.

Агымдагы елның 9 аенда 109 шундый һәлакәт теркәлгән. Иң күп очраклар Алабуга, Питрәч, Әлмәт һәм Чистай районнарында булган. Мондый очракларда хайваннар гына түгел, машина йөртүчеләр һәм пассажирлар да зыян күрә.

Комитет машина йөртүчеләргә тизлек режимын үтәргә, сак һәм игътибарлы булырга, кыргый хайваннар күчеше мөмкин булган урыннар турында мәгълүмат бирә торган юл билгеләренә карарга кирәклеген искәртә.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ГЛОБАЛЬ АВАРИЯМЕ, ТЕХНИК ХАТА ГЫНАМЫ?

4 октябрь киче социаль челтәрләргә бәйлелектән интеккән халык өчен зур уңайсызлык тудырды: 3 миллиард чамасы кулланучысы булган Facebook пәрәвезе, аның кушымталары булган WhatsApp һәм Instagram эштән туктадылар. Дөньяның иң бай кешесе исәпләнгән Цукерберг мөлкәтендәге барлык сервисларның берьюлы өзелүе планета күләмендәге зур авария булып тарихка язылды инде. Мондый өзеклек 2008 елда бер күзәтелгән, әмма ул чакта Facebook кулланучылары саны 80 миллион гына булган. Социаль челтәрләрнең түнтәрелеше Цукербергны 6 миллиард доллардан артык спекулятив табыштан мәхрүм итте. Аның акцияләренең куыгы шулай зур күләмдә шиңде. Әмма түнтәрелеш Facebook хуҗасы югалтулары белән генә чикләнмәде. Нью-Йорк биржасында югары технологияле компанияләрнең зур мәтәлчеген китереп чыгарды. Nasdaq Composite, мәсәлән, берничә сәгать эчендә 2,2 процентка ябыкты.

Техник өзеклек бер Facebook белән генә чикләнмәде ләкин. АКШның иң зур мобиль элемтә операторлары AT&T, Verizon һәм T-Mobile үз сервисларының ватылуы турында хәбәр иттеләр. Россия провайдерлары һәм элемтә операторлары «Ростелеком», МГТС, МТС, «Мегафон», Yota, Tele2 һәм «Билайн»нар да тизлекнең акрынаюын һәм өзеклекләр барлыкка килүен таныдылар. Башка интернет сервисларда да берникадәр проблемалар туды.

5 октябрь көнне иртән Facebook хуҗалары катастрофаның программа конфигурациясендә уңышсыз үзгәрешләр кертелү нәтиҗәсендә тууын әйтеп, гафу үтенделәр, кулланучылар турындагы мәгълүмат читкә китмәде, дип ышандырдылар. Әмма… ышанмаска рөхсәт итегез. Мондый вакытта рәсми мәгълүмат йөз аклыгын саклау өчен тарата. Цукербергның миллиардларыннан бөтенләй колак кагасы килми бит инде. Беренчедән, даркнетта (интернетның гомум кулланучылардан яшерелгән сегменты) авариягә кадәр үк инде 1,5 миллион кулланучының мәгълүмат базасы сатуга куелды дигән хәбәр таратылды. Икенчедән, Цукерберг челтәрендәге хата ни өчен әле интернетның башка өлкәләрендә дә түнтәрелеш китереп чыгара? Социаль челтәрләр генә түгел, Nyse, Nasdaq, Moex кебек биржаларның да сайтлары берьюлы эштән туктады бит. Хәтта авиация компанияләре үз онлайн-сервисларының бозылуын әйттеләр. Bank of America – АКШның зурлыгы ягыннан икенче урында торган банкы үз сервисларының эштән туктавын таныды һәм моның Американың бөтен финанс секторын түнтәрергә мөмкин икәнлеген әйтте. Пентагон милли куркынычсызлык контекстында вазгыятьне контрольгә алырга тырышуын рәсми рәвештә игълан итте. Бер кызыклы мәгълүмат бар: интернет-форумнарның берсендә Facebook түнтәрелешеннән 15 минут алда бер билгесез кеше социаль челтәрләрнең глобаль түнтәрелеше башланачагы турында хәбәр калдыра. Биржа графиклары Цукерберг компаниясенең акцияләре өзеклек башланганчы ук түбәнгә тәгәрәвен күрсәтәләр. Димәк, авария турында биржа спекулянтларының бер өлеше алдан кисәтелгән. Төнлә интернет киңлегендә: «Спутниклар (ясалма иярченнәр) яулап алына. Электр өзеләчәк», – дигән янаулы хәбәр дә пәйда булды хәтта. Бу соңгысы вазгыятьне файдаланып, паника тарату гына булгандыр, бәлки. Әмма социаль челтәрләр түнтәрелешеннән күп сәгатьләр алда Кытайда Чжэнчжоу шәһәрендәге шоу вакытында, идарә югалу сәбәпле, йөзләгән дрон берьюлы яңгыр булып җиргә коелды. Әле ярый зур фаҗига булмады. Болар барысы да электрон сервисларның ышанычсыз булуын, зур һөҗүм оештырылып, бөтен планетаның берьюлы элемтәсез калуы, электр энергиясе һәм газ өзелү куркынычы, финанс секторының эштән чыгуы бик мөмкин хәл икәнен искәртә.

Россиядә

АЛТЫН БЕТСӘ БЕТӘР, ЭШЛӘҮЧЕЛӘР БЕТМӘСЕН

Соңгы вакытларда углеводородларга бәянең кискен артуы сәбәпле, илдә икътисад проблемалары баш калкытып тора. Банклар ипотека ставкасын күтәрә башладылар. Бу төзелеш шаукымының кимеп, материаллар җитештерүче заводларның һәм төзелеш компанияләренең эше акрынаюга китерер, мөгаен. Үзәк банк төп ставканы тагын да күтәрәчәк. Бизнес моңа шикләнми. Димәк, кредит процентлары да үсүдән туктамас. Икътисадның реаль секторы өчен зур проблемага әвереләчәк бу хәлләр.

Җитмәсә, илнең иң зур алтын чыгаручы компанияләренең берсе булган «Полюс» компаниясе җитәкчесе Павел Грачев Россиядә җир астындагы алтын чыганакларының бетүгә таба баруын әйтеп куркыта. Юк, алтын күп ул үзе. Галимнәр, планета тирәнлекләрендәге бөтен алтын өскә чыкса, бар җирдә дә тездән булачак, атлап йөреп булмаячак, диләр. Тик кыйммәтле металл үзеннән-үзе өскә калыкмый бит инде. Аның ятмаларын башта эзләп табарга, аннан инвестицияләр ясап чыгарырга кирәк. Россиядә менә шул эзләп табу мәсьәләсендә эшләр хөрти икән. Катлаулылык шунда: разведка компаниясенә ятмаларны эзләү файдалы түгел, чөнки син тапкан ятманы сатуга куялар да, бүтән берәү аңа хуҗа була.

Сатарга чимал бетсә, бюджетны тутыруның бердәнбер юлы булып эшче халык җилкәсенә өелгән салымнар калачак бит. Бу өлкәдә дә проблемалар бар, диләр салым җыючылар. Үзмәшгульләр турында канун кабул ителгәч, яхшы булды, дип сөенделәр. Кешеләргә күләгәдән чыгып, закон каршына бастырылудан курыкмыйча эшләү мөмкинлеге бирү начар түгел начарлыкка. Печтек кенә салым түлисең дә, тыныч йоклыйсың. 3 миллион россияле хәзерге көндә шулай тыныч йоклый башлаган. Шулаен ул шулай да, ярый да эшләр барса уңайга, диләр бит әле. Салым җыючылар эшләр уңайга бармый дип саныйлар әнә. Мәсьәләнең кыен ягы шунда: бизнес халыкны эшкә яллагыйча, үзмәшгуль итеп кенә файдаланырга ияләнгән. Икеяклы килешү төзисең дә эшләгәненә түлисең, ә салым түләп мәшәкатьләнүдән азат буласың. Хезмәт кенәгәсе белән эшкә алсаң, хезмәт хакыннан 13 процент НДФЛ, 30 процент социаль взнослар түләргә кирәк булачак. Түгәрәк кенә суммага җыела ул. Эш бирүчеләр җайлы юлны файдаланырга яраталар, әлбәттә. Федераль салым оешмасы моннан бер дә канәгать түгел, шуңа күрә бизнесны тикшерү өчен зур рейдлар ясарга ниятли. Бу хакта аның 16 сентябрьдә язылган N АБ-4-20/13183 тамгалы хатын укып белеп була.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

ХЕЗМӘТЕГЕЗ ӨЧЕН РӘХМӘТ!

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Токиода узган Җәйге Олимпия Уеннары җиңүчеләре һәм призерларын котлап, аларга дәүләт бүләкләре тапшырды.

– Олимпия уеннарында уңышлы чыгыш ясавыгыз белән котлыйм. Ярышларның пандемия аркасында озак вакыт тәнәфестән соң узуына карамастан, сез осталык, максатчанлык күрсәттегез, җиңүгә омтылдыгыз, – диде республика җитәкчесе спортчыларны тәбрикләп.

Рөстәм Миңнеханов Олимпия Уеннарында катнашучыларның уңышлары бәрабәренә Татарстан тагын да күбрәк танылды дигән фикердә. Бу, әлбәттә, тренер һәм спортчыларның тырышлыгы нәтиҗәсе.

– Сезнең өчен бөтен ил җан атты. Сезнең уңышларыгыз – яшь спортчылар, спорт мәктәпләре, түгәрәкләрдә шөгыльләнүче малайлар һәм кызлар өчен яхшы үрнәк. Алга таба да бу юнәлешне үстерүдә эш алып барылачак, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Сүз уңаеннан, республикада барлыгы 11 меңнән артык спорт корылмасы бар. Күпчелеге дөньякүләм стандартларга туры килә. «Алга таба да спорт комплекслары, йөзү бассейннары, боз сарайлары төзүне, аларны кирәкле заманча җиһазлар белән тәэмин итүне дәвам итәчәкбез», – диде Президент.

Татарстан Президенты Указы нигезендә ил спортын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм Олимпия Уеннарында югары казанышлары өчен спортчыларга «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен», «Дуслык» ордены, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале тапшырылды.

Рөстәм Миңнеханов та бүләксез калмады. Хатын-кызлар арасында рапира буенча команда ярышында алтын медаль иясе Марта Мартьянова аңа рапира һәм шлем бүләк итте.

* * *

Традицияләр дә саклана, яңалык та өстәлә. Татарстандагы мәгариф тармагын шулай тасвирлап булыр иде. Һөнәри бәйрәм көнендә укытучылар Татарстан Президентыннан котлау сүзләре кабул итте.

Татарстан мәгариф системасы бай тарихка ия. Ул үз эчендә Европа, Россия һәм үзебезнең милли гореф-гадәтләрне берләштерә. Республика Президенты Рөстәм Миңнеханов «Пирамида» комплексында узган Халыкара укытучы көненә багышланган чарада шулай диде. Аның фикеренчә, мондый система киләчәккә ышанычлы карарга мөмкинлек бирә.

– Инфраструктура булдыру, кадрлар мәсьәләсен хәл итү югары белем бирү сыйфатын, аның эзлеклелеген һәм дәвамлылыгын тәэмин итәргә булыша. Укытучыларның профессиональлеге, осталыгы нәтиҗәсендә быел республикада бердәм дәүләт имтиханында 257 бала 100 балл җыйды. Бу узган ел белән чагыштырганда 18гә күбрәк. Әлеге күрсәткеч белән без Россиянең иң яхшы биш төбәге арасына кердек. 9 ел дәвамында без Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасы нәтиҗәләре буенча призерлар рәтендә торабыз, Мәскәү һәм Санкт-Петербургтан гына калышабыз, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстан халыкара олимпиадаларда ил данын да лаеклы яклый. Бу җәһәттән Президент WorldSkills Russia җиңүчеләрен искә төшерде. Татарстан җыелма командасы илкүләм чемпионат финалында I урынны яулаган иде.

– Без укучыларыбызның һәм укытучыларыбызның казанышлары белән горурланабыз. Татарстан Хөкүмәте педагогик хезмәтнең статусын һәм абруен күтәрү өчен кулдан килгәннең барысын да эшли, укытучылар хезмәтен бәяләү һәм мәктәпләргә яшь белгечләрне җәлеп итүгә юнәлдерелгән проектлар гамәлдә, – диде Рөстәм Миңнеханов һәм укытучыларга рәхмәт әйтеп, сәламәтлек, уңышлар теләде.

Өй туйларына бай ел

Илдар Мөхәммәтҗанов

Торак

Башкала хакимиятенең иң авырткан урыннарының берсенә әверелгән авария хәлендәге торактан күчерү мәсьәләсе якын арада тулысынча хәл ителергә мөмкин. Казан мэры Илсур Метшин сүзләре белән әйтсәк, тоннель ахырында яктылык күренә башлаган инде.

– Халыкны авария хәлендәге торактан күчерү программасын тормышка ашыру вакыты кыскарды. Элегрәк ул алты этапта башкарылган булса, бүген дүрт баскычта тормышка ашырыла. Якын киләчәктә әлеге программаны йомгакларбыз дип өметләнәм, – дип белдерде ул Казан шәһәр думасы утырышында.

Гомумән алганда, агымдагы елның 9 аенда башкалада яшәүче 1,1 мең гаилә торак шартларын яхшырткан. Моның өчен республика һәм федераль бюджеттан 1,6 миллиард сум акча сарыф ителгән. Соңгы биш елда торак шартларын яхшырткан гаиләләр саны 13 меңнән арткан. Казан шәһәренең торак сәясәте идарәсе җитәкчесе Ренат Шәмсетдинов сүзләренә караганда, ел башыннан бирле 2265 алданган өлешче дә еллар буе өметләнеп көткән фатир ачкычларын алган. «Халыкның торак шартларын яхшырту – шәһәрнең социаль-икътисади үсешендә иң өстенлекле юнәлешләрнең берсе булып тора. Бу максатка ирешү өчен Татарстан башкаласында төрле республика һәм муниципаль программалар тормышка ашырыла», – дип билгеләп үтте ул үз чыгышында.

Ренат Шәмсетдинов белдерүенчә, бүген Казанда торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә алынган барлык ветераннар һәм аларның гаилә әгъзалары торак белән тәэмин ителгән. Бу максатка барлыгы 1,5 млрд сум акча бүлеп бирелгән. Әлеге программа эшли башлаган 2006 елдан бирле 1624 гаилә үзләренең торак шартларын яхшырткан. «Коммерция базарында торак сатып алу өчен субсидия акчасы җитәрлек булмау сәбәпле, республика җитәкчелеге ветераннарга бары тик субсидия хисабына социаль ипотека программасы буенча төзелгән йортларда 36 кв. м мәйданлы бер бүлмәле фатирлар сатып алу мөмкинлеген бирергә карар кылды», – ди идарә җитәкчесе. Дөрес, ветеран ике яки өч бүлмәле фатир да сатып алырга мөмкин. Әмма бу очракта аңа торак бәясендәге аерманы үзенә түләргә туры киләчәк.

Шулай ук дәүләт программасы кысасында федераль бюджеттан хәрби хәрәкәтләр ветераннарына, хәрби хезмәттән азат гражданнарга, Чернобыль атом электростанциясендәге авария нәтиҗәләрен юк итүдә катнашкан, Ерак Төньяк районнарыннан чыгып китәргә мәҗбүр булган кешеләрне торак белән тәэмин итү өчен дә акча бирелә. 2010 елдан әлеге категориядәге 1032 кеше 900 млн сумга үзләренең торак шартларын яхшырткан. Ренат Шәмсетдинов сүзләренә караганда, хәзерге вакытта хәрби хезмәттән азат кешеләрнең торак белән тәэмин итү буенча чираты бетерелгән диярлек.

Бер йодрыкка тупланыр чак

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Җанисәпкә багышланган матбугат очрашуында катнашкан журналистлар әнә шул сорауга да ачыклык кертергә тырышты. Әмма белгечләр бу уңайдан төгәл генә җавап бирә алмады. Наталья Гатауллина бу урында: «Ахыргы нәтиҗәләр чыгарганда, гражданнар язган һәр җавап исәпкә алыначак», – дию белән генә чикләнде. Халык саны нәтиҗәләре буенчаербөтен, бердәм булып калуыбыз үзебездән – тамырларыбызны тәгаен күрсәткән, «мин – татар» дигән төгәл җавабыбыздан тора, димәк.

Үзеңнең кемлегеңне исә берничә төрле ысул белән белдереп була. Быелгы халык санын алу өч төрле юл белән узачак. Беренчесе – елның-елында күзәтелә торган традицион юл: махсус киемнән булган сораучы өйдән-өйгә йөреп, фәлән адрес буенча яшәгән һәркем турында тулы мәгълүмат туплый. Халык санын алып йөргән бу белгечләрдән куркырга кирәкми. Татарстанстат җитәкчесе сүзләренә караганда, җанисәптә сорау бирүчеләрнең 70 проценты – коронавирустан прививка ясаткан яисә авырып терелгән кешеләр. Димәк, алар вирус йоктырырга мөмкин дип куркырга сәбәп юк. Өстәвенә аларның һәркайсы битлек, пирчәткәдән булачак.

Өенә чит кеше кертергә теләмәүчеләр исә халык санын алуда моның өчен билгеләнгән махсус стационар урыннарга барып та катнаша ала. Алар, нигездә, күпфункцияле үзәкләрдә урнашачак. Стационар пунктлар 18 октябрьдән 14 ноябрьгә кадәр эшләячәк.

Башка еллардан аермалы буларак, быел җанисәптә онлайн рәвештә дә катнашырга мөмкин. Бу мөмкинлектән 15 октябрьдән 8 ноябрьгә кадәр файдаланырга була. Моның өчен кешенең дүләт хезмәтләре порталында шәхси сәхифәсе булу мәҗбүри. Алга таба «Халык санын алуда катнашу» дигән махсус төймәгә басып, җанисәп битендәге төп сорауларга җавап биреп чыгарга кирәк. Гаиләдән бер кеше бөтен гаилә әгъзалары өчен җавап биреп чыкса да ярый. Халык санын алуга бәйле сорауларга җавап биреп бетергәч, анда катнашкан һәркемгә QR-код җибәреләчәк. Ул җанисәптә катнашканлыкны раслый. QR-код халык санын алучыларның базасына да җибәреләчәк. Өйгә килгән халык санын алучыга да шул кодны күрсәтәсе булачак. Ул аны базага килгән мәгълүмат белән чагыштырачак. Халык санын алу белән бәйле беренче нәтиҗәләр декабрьдә билгеле булыр дип фаразлана.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

БАЛАЛАР... СЫР ЯСЫЙ

Һөнәр

Россиядә беренче балалар сыр кайнату цехы Татарстанның Минзәлә районында эшли башлады. Балалар интернаты базасында сыр ясау серләренә өйрәтәләр һәм мастер-класслар күрсәтәләр.

Минзәләнең ятимнәр һәм мөмкинлекләре чикле балалар өчен мәктәп-интернатының директор урынбасары Светлана Мәхмүтова безгә әйтүенчә, цехта укучылар сыр кайнату серләренә төшенә һәм киләчәккә һөнәр сайлый.

Интернат, «Ак Барс Созидание» хәйрия фонды ярдәме белән, 1 млн 800 мең сумлык грант оталар. Һәм әлеге акчага зур булмаган сыр кайнату цехы төзелә.

Ул интернат базасында булса да, бинасы мәктәп янында урнашкан.

– Әлеге проектның төп максаты – өлкән сыйныфта укучы балаларга бу профессия буенча белем бирү, эш тәртибенә өйрәтү. Безнең интернатның өлкән сыйныфларында авыл хуҗалыгы тармагы тирәнтен өйрәнелә. Аның бер өлкәсе – үсемлекчелек, икенчесе – терлекчелек. Үсемлекчелек тармагы буенча ел дәвамында эшли торган теплицабыз һәм бакчабыз бар. Анда яшелчә, җиләк-җимеш үстерәбез. Көзен теплицада үскән уңышны җыеп алып эшкәртәбез. Ә инде икенче тармак итеп без сыр кайнатуны алдык, – диде Светлана Мәхмүтова.

Әлеге цехны профильле укыту алдыннан балаларны профессия белән таныштыру буларак та кабул итәргә мөмкин. Теория өлеше мәктәптә узса, гамәли өлеше әлеге бинада узар, дип планлаштыралар. Әлеге белемнәрне балаларга технолог бирә. Әлеге вакытта мөмкинлекләре чикле укучылар 6 төрле сыр ясап караган. Алар арасында «Адыгей», фета, рикотта да бар.

– Безнең планнар зурдан. Акрынлап сырларның сортларын арттырырбыз дип уйлыйбыз. Лицензия булса, бәлки, укучылар ясаган продукцияне сатуга да чыгара алырбыз. Киләчәген планлаштырганда монда алган белемнәре балаларга ярдәм итәр дип өметләнәбез, – ди җитәкче.

Сөтне фермер хуҗалыгыннан алып киләләр. Сыр ясау өчен бер көнне 50 литр сөт файдаланыла. Мондый дәресләр айга 3 тапкыр үткәрелә.

Әлеге цех августта ачылган. Укучылар инде үзләре җитештергән сырларны төрле ярминкәләрдә дә тәкъдим итәргә өлгергән. Төрле чараларда катнашып, халыкка балалар әзерләгән ризыкларны тәмләп карау мөмкинлеге тудырылган.

Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы хәбәр итүенчә, мондый зур булмаган сыр кайнату цехлары киләчәктә республиканың тагын берничә районында ачылачак. Аның максаты – мөмкинлекләре чикле балаларга әлеге авыр һөнәрнең нечкәлекләренә төшенергә булышу һәм тормышта күңелләре яткан хезмәтне табу.

Зөһрә САДЫЙКОВА



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), «бер яисә берничә документы составында» сүзләреннән соң «, шулай ук әлеге Законның 4 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән бер яисә берничә өлкәгә карата» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 04 октябрь
№ 68-ТРЗ

«Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» 2005 елның 29 декабрендәге 134-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, № 3; 2013, № 5; 2014, № 5, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 76 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда «федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары» сүзләрен «Һәлакәттән коткару хезмәтләре турында һәм коткаручылар статусы хакында» 1995 елның 22 августындагы 151-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон), башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары» сүзләренә алмаштырырга;

2) 8 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Федераль законның 5 статьясы нигезендә төрләре билгеләнгән һәлакәттән коткару эшләрен үткәрү чорында коткаручылар хезмәтен саклау таләпләре һәлакәттән коткару эшләрен үткәрү кагыйдәләрен, процедураларын, критерийларын һәм нормативларын билгели торган норматив хокукый актлар белән регламентлаштырыла.»;

3) 21 статьяның 1 өлешендә «аеруча кирәк очракта» сүзләрен төшереп калдырырга.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 04 октябрь
№ 69-ТРЗ

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 12 (II өлеш); 2010, № 5 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 3, № 10; 2014, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 92 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»;

2) преамбулада «күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча» сүзләрен «күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

3) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 статья. **Җирле үзидарә органнарына бирелә торган дәүләт вәкаләтләре**

Җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә түбәндәге Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре (алга таба – дәүләт вәкаләтләре) бирелә:

1) торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасын кулланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә төзүченең һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Федераль закон) 3 статьясындагы 1^1 һәм 2 өлешләрендә, 3^2, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү йә мондый бәяләмә бирүдән дәлилләнгән баш тартуны тапшыру;

2) төзүчедән корпоратив юридик затның – төзүченең турыдан-туры яисә читләтеп (өченче затлар аркылы) ахыр чиктә хуҗасы булган (капиталда катнашуы биш проценттан артык булган) физик зат турында мәгълүмат алу;

3) төзүчедән федераль башкарма хакимиятнең күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт җайга салуын гамәлгә ашыруга вәкаләтле органы билгеләгән тәртиптә һәм срокларда, юридик затның тулы исемен яисә индивидуаль эшкуарның фамилиясен, исемен, атасының исемен (булганда), адресын (урнашкан урынын) күрсәтеп, эшләр башкаручы, товарлар ташучы һәм (яисә) инженер эзләнүләре үткәрү, архитектура-төзелеш проектлавы һәм төзелеш хезмәтләрен күрсәтүче затлар, шулай ук мондый товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең төрләре турында һәм, Россия Федерациясе законнарында күрсәтелгән эш төрләрен башкаруга, товарлар ташуга һәм хезмәтләр күрсәтүгә тиешле рөхсәтләр (лицензияләр) булу таләбе каралган очракта, бу затларда күрсәтелгән рөхсәтләр (лицензияләр) булу хакында мәгълүмат алу;

4) башкарма хакимиятнең Россия Федерациясендә социаль, икътисадый, демографик, экологик һәм башка иҗтимагый процесслар турында рәсми статистик мәгълүмат формалаштыру функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль органыннан һәм аның территориаль органнарыннан төзүчеләрнең күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге турында документлар һәм мәгълүмат, шулай ук торак-төзелеш кооперативының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге турында документлар һәм мәгълүмат алу;

5) федераль башкарма хакимиятнең салымнар һәм җыемнар турындагы законнар үтәлешен тикшереп тору һәм күзәтчелек итү функцияләрен гамәлгә ашыручы органыннан ведомствоара мәгълүмати үзара эшчәнлек тәртибендә юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (андагы белешмәләрне), Федераль законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 7 пунктында билгеләнгән таләпләрнең төзүче тарафыннан үтәлүен тикшереп тору өчен кирәкле документлар һәм мәгълүмат, шулай ук торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күпфатирлы йорт төзү өчен торак-төзелеш кооперативының гражданнарның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге турында документлар һәм мәгълүмат алу;

6) федераль башкарма хакимиятнең эчке эшләр өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү, гамәлгә ашыру һәм норматив хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы органыннан ведомствоара мәгълүмати үзара эшчәнлек тәртибендә Федераль законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 8 пунктында билгеләнгән таләпләрнең төзүче тарафыннан үтәлүен тикшереп тору өчен кирәкле документлар һәм мәгълүмат, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 116^1 статьясындагы 1 пунктында билгеләнгән документлар һәм мәгълүмат алу;

7) федераль башкарма хакимиятнең дәүләт кадастр исәбенә алуны, хокукларны дәүләт теркәвенә алуны, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып баруны гамәлгә ашыручы органыннан (алга таба – хокукларны теркәү органы) һәм аның территориаль органнарыннан төзүчеләрнең күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген, шулай ук торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күпфатирлы йорт төзү өчен торак-төзелеш кооперативының гражданнарның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге турында документлар һәм мәгълүмат алу;

8) төзүчедән күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру, шул исәптән төзүченең төзелеш проектларын гамәлгә ашыруның якынча графикларын, килешүләр буенча йөкләмәләрен, төзелеш проектының җыелма тупланма исемлеген үтәве турында, шулай ук Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзелгән арадаш һәм еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын алу;

9) торак-төзелеш кооперативыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән рәвешләрдә һәм тәртиптә торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күпфатирлы йорт төзү өчен торак-төзелеш кооперативының гражданнарның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген гамәлгә ашыру, шул исәптән мондый кооперативның кооператив әгъзалары һәм башка затлар каршындагы үз йөкләмәләрен үтәве турында квартал саен хисаплылык алу, шулай ук Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзелгән арадаш һәм еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын алу;

10) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган нигезләмәләр нигезендә күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген), шулай ук торак-төзелеш кооперативының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлегенә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру;

11) Россия Федерациясе Үзәк банкыннан төзүче тарафыннан поручительлек килешүе төзелгән банкның йә «Россия Федерациясендә иминият эшен оештыру турында» 1992 елның 27 ноябрендәге 4015-1 номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә Россия Федерациясе территориясендә иминият эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукына ия булган, төзүче белән иминият килешүе төзегән иминият оешмасының яисә чит ил иминият оешмасының Федераль закон таләпләренә туры килүе турында соратып алуны гамәлгә ашыру, шулай ук гражданнарның һәм юридик затларның Федераль закон бозылуга бәйле шикаятьләрен карау;

12) үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында төзүче, торак-төзелеш кооперативы эшчәнлегенә карата уздырылган тикшереп тору (күзәтчелек) чаралары турында мәгълүмат, файдалануы Россия Федерациясе законнары белән чикләнгән белешмәләрдән тыш, урнаштыру, шулай ук төзүчене, аның вазыйфаи затларын Федераль закон таләпләрен бозган өчен административ җаваплылыкка тарту хакында үз көченә кергән карарлар турында белешмәләр, торак-төзелеш кооперативын, аның вазыйфаи затларын Россия Федерациясе Торак кодексы таләпләрен һәм законнарда билгеләнгән башка таләпләрне бозган өчен административ җаваплылыкка тарту хакында белешмәләр урнаштыру;

13) төзелеш өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче затларны (аларның вазыйфаи затларын), торак-төзелеш кооперативларын (аларның вазыйфаи затларын) Федераль законда һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән җаваплылыкка тарту өчен кирәкле чаралар күрү;

14) өлешле төзүдә катнашучыларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен, шулай ук үз акчалары белән күпфатирлы йортны төзүдә катнашучы торак-төзелеш кооперативы әгъзаларының Россия Федерациясе Торак кодексының 11 бүлегендә каралган хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклап, мондый хокуклар һәм законлы мәнфәгатьләр бозылган очракта, гаризалар белән судка мөрәҗәгать итү;

15) мәҗбүри таләпләрне бозуның җинаять җаваплылыгына тартырлык гамәлләр кылу билгеләре булган фактлары ачыклануга бәйле материалларны җинаять эшләре кузгату турындагы мәсьәләләрне хәл итү өчен хокук саклау органнарына җибәрү;

16) Федераль законның 23 статьясындагы 15 һәм 16 өлешләрендә билгеләнгән очракларда, төзүченең күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыруын билгеле бер вакытка туктатып тору турындагы гариза белән йә төзелеш өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче затны ликвидацияләү хакындагы гариза белән арбитраж судка мөрәҗәгать итү;

17) торак-төзелеш кооперативы идарәсе органнарыннан ачыкланган җитешсезлекләрне бетерүне таләп итү;

18) торак-төзелеш кооперативы тарафыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 110 статьясындагы 3 өлеше, күпфатирлы йортны алга таба карап торудан тыш, һәм Россия Федерациясе Торак кодексының 123^1 статьясы таләпләрен бозуга карата гражданнарның һәм юридик затларның шикаятьләрен карау;

19) торак-төзелеш кооперативына Россия Федерациясе Торак кодексының 110 статьясындагы 3 өлеше, күпфатирлы йортны алга таба карап торудан тыш, һәм Россия Федерациясе Торак кодексының 123^1 статьясы таләпләре бозылуны бетерү турында үтәү өчен мәҗбүри булган күрсәтмәләр юллау һәм мондый таләп бозуларны бетерү срокларын билгеләү;

20) торак-төзелеш кооперативы әгъзалары реестрында булган белешмәләрне, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 123^1 статьясында каралган башка мәгълүматны торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасыннан алу;

21) торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасына Федераль законның 23^3 статьясындагы 5 һәм 6^2 өлешләрендә күрсәтелгән мәгълүматны урнаштыру;

22) хокукларны теркәү органына Федераль законның 3 статьясындагы 2^6 өлешендә каралган хәбәрнамәләр җибәрү;

23) вәкаләтле банктан төзүчеләргә карата күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә соратып алуны гамәлгә ашыру;

24) күпфатирлы йортның һәм (яисә) башка күчемсез мөлкәт объектының (төзелеш проектының) әзерлек дәрәҗәсе һәм Федераль законның 15^4 статьясында каралган счетларны кулланмыйча гына өлешле төзелештә катнашу шартнамәләрен төзү мөмкинлеге булу турында бәяләмә (алга таба – критерийларга туры килү турында тикшереп тору органы бәяләмәсе) бирү, критерийларга туры килү турында тикшереп тору органы бәяләмәсен бирү хакында гаризаны, критерийларга туры килү турында тикшереп тору органы бәяләмәсен яисә критерийларга туры килү турында тикшереп тору органы бәяләмәсен бирүдән баш тарту хакында документны, тиешле карар кабул ителгән көннән соңгы өч эш көненнән дә соңга калмыйча, торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасына урнаштыру.»;

4) 4 статьяның 2 өлешендә «Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча» сүзләрен «күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

5) 6 статьяда:

а) 1 өлешнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт төзелеш күзәтчелеге өлкәсендә вәкаләтле органыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны (шул исәптән күпфатирлы йортны төзүгә бәйле документларны) соратып алырга;»;

б) 2 өлешнең 5^1 пунктында «егерме бишенче абзацында» сүзләрен «16 пунктында» сүзләренә алмаштырырга;

6) 7^1 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

7) кушымтада:

а) «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына кушымта»

сүзләрен

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына кушымта» сүзләренә алмаштырырга;

б) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен билгеләү методикасы».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 04 октябрь
№ 70-ТРЗ

«Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» 1999 елның 17 ноябрендәге 2440 номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 3 пунктының беренче абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 1 (1); 2001, № 3; 2004, № 3 (IV өлеш); 2005, № 4 (I өлеш), № 7 – 8; 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3, № 6 (I өлеш); 2013, № 6 (II өлеш), № 11 (II өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 54 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 37 (I өлеш); 2021, № 49 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3. Җәмәгать судьясының вәкаләтләре туктатылганда яисә туктатып торылганда, шулай ук җәмәгать судьясы вакытлыча урынында булмаган (авыру, чираттагы ял һәм башка нигезле сәбәпләр) башка очракларда аның вазыйфаларын башкару тиешле район суды рәисе карары белән шул ук суд районының башка суд участогы җәмәгать судьясына йөкләнә. Әгәр суд районында күрсәтелгән нигезләр буенча урынында булмаган җәмәгать судьясы вазыйфаларын шул ук суд районының башка җәмәгать судьясына йөкләү мөмкин булмаса (суд районында җәмәгать судьясы урыны бары бер генә булса яисә суд районының башка җәмәгать судьялары вакытлыча урыннарында булмаса), аның вазыйфаларын башкару югарыдагы суд рәисе яисә аның урынбасары карары белән үз эшчәнлеген иң якындагы суд районында башкаручы җәмәгать судьясына йөкләнә.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 04 октябрь
№ 71-ТРЗ

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, №7–8 (I өлеш), № 9–10, № 12 (I өлеш); 2010, №1–2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1–2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7; 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш); 2016, № 5, № 7–8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 85 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 2.18 статьяны өстәргә:

«2.18 статья. **Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе карарын яисә күрсәтмәсен үтәмәү**

Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе карарын яисә күрсәтмәсен үтәмәгән йә үтәү срогын бозган өчен, административ хокук бозу турындагы эш буенча карардан йә Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 29.13 статьясында каралган тәртиптә чыгарылган күрсәтмәдән тыш, –

гражданнарга – бер меңнән алып ике мең сумга кадәр, вазыйфаи затларга – ике меңнән алып биш мең сумга кадәр, юридик затларга ун меңнән алып егерме мең сумга кадәр административ штраф салына.»;

2) 7.1 статьяда «2.11 – 2.17» саннарын «2.11 – 2.18» саннарына алмаштырырга;

3) 8.1 статьяга түбәндәге эчтәлекле 7^2 өлеш өстәргә:

«7^2. Әлеге Кодексның 2.18 статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча тиешле комиссияләрнең рәисләре, аларның урынбасарлары төзи.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 04 октябрь
№ 72-ТРЗ

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 4 (I өлеш); 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 94 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 статьяның 10 пунктында «чикләү, вакытлыча чикләү яки туктату» сүзләрен «вакытлыча чикләү яисә вакытлыча туктату» сүзләренә алмаштырырга;

2) 12 статьяның 6 пунктында «, капиталь ремонтлауга» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 13 статьяның 1 пунктында «яисә капиталь ремонтлауга» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 25 статьяда:

а) 4 өлештә «хосусый» сүзен төшереп калдырырга;

б) 4^1 өлештә «хосусый» сүзен төшереп калдырырга;

5) 26 статьяның 3 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле 1^1 пункт өстәргә:

«1^1) авыл җирлеге территориясендә урнашкан хосусый автомобиль юлларына карата – авыл җирлегенең җирле үзидарә органы тарафыннан;»;

б) 2 пунктта «җирлекнең» сүзен «шәһәр җирлегенең» сүзләренә алмаштырырга, «ашыру җирлек» сүзләрен «ашыру шәһәр җирлеге» сүзләренә алмаштырырга;

6) 28 статьяда:

а) 1 өлештә «хәрби техника, транспорт чаралары» сүзләреннән соң «, федераль иминлек хезмәте органнары транспорт чаралары, шулай ук махсус ут һәм тавыш сигналлары бирү өчен җайланмалар куелган һәм гадәттән тыш хәлләргә оператив чара күрү, аларны кисәтү һәм алардан килгән зыянны бетерү максатларында янгыннан саклау, һәлакәттән коткару хезмәтләре, һәлакәттән коткару формированиеләре эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган махсус транспорт чаралары» сүзләрен өстәргә;

б) 4 өлешнең беренче җөмләсендә «тәэмин итү өлкәсендәге» сүзләреннән соң «махсус» сүзен өстәргә.

2 статья

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 6 пунктының «а» пунктчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 6 пунктының «а» пунктчасы 2021 елның 30 декабреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 04 октябрь
№ 73-ТРЗ

Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 45 статьясына һәм «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 14 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 45 статьясындагы 2^1 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 60 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2^1. Бала бертуганнары һәм атасы йә анасы башка булган абыйсы һәм (яисә) апасы укый торган дәүләт яисә муниципаль мәгариф оешмаларына мәктәпкәчә белемнең һәм башлангыч гомуми белемнең төп гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга өстенлекле кабул ителү хокукына ия.».

2 статья

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешендәге 15^3 пунктында «максатчан укыту турындагы шартнамәнең якларын» сүзләрен «максатчан укытуга заказ бирүчене» сүзләренә алмаштырырга;

2) 14 статьяның 2^1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2^1. Бала бертуганнары һәм атасы йә анасы башка булган абыйсы һәм (яисә) апасы укый торган дәүләт яисә муниципаль мәгариф оешмаларына мәктәпкәчә белемнең һәм башлангыч гомуми белемнең төп гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга өстенлекле кабул ителү хокукына ия.».

3 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 04 октябрь
№ 74-ТРЗ

Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 4 (I өлеш); 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 94 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 статьяның 15^1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15^1) автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында региональ дәүләт тикшереп торуы (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау;»;

2) 12 статьяның 1 пунктында «Региональ әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итү өчен региональ дәүләт күзәтчелеген» сүзләрен «автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында региональ дәүләт тикшереп торуын (күзәтчелеген)» сүзләренә алмаштырырга;

Ахыры 4 нче биттә >

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

Ахыры. Башы 3 нче биттә >

3) 13 статьяда:

а) 1^1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1^1) автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы нигезләмәне раслау;»;

б) 2 пунктта «җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының саклануышын тәэмин итү өчен» сүзләрен «автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында» сүзләренә алмаштырырга;

4) 13^1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13^1 статья. **Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында региональ дәүләт тикшереп торуы (күзәтчелеге), муниципаль контроль**

1. Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты, автомобиль юллары, юл хуҗалыгы өлкәсендә федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль норматив хокукый актларда, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләрендә, Евразия икътисадый союзы хокукын тәшкил итүче актларда автомобиль юллары сакланышы өлешендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында региональ дәүләт тикшереп торуы (күзәтчелеге), муниципаль контроль түбәндәгеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла:

1) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган нигезләмәгә таянып, вәкаләтле орган;

2) муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары тарафыннан раслана торган нигезләмәләргә таянып, җирле үзидарәнең вәкаләтле органнары.

2. Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында региональ дәүләт тикшереп торуын (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләре яисә аларны башкару буенча аерым вәкаләтләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, җирле администрация башлыгы карары белән дәүләт учреждениеләренә, муниципаль учреждениеләргә йөкләнергә мөмкин.

3. Әлеге статьяның 2 өлеше нигезендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында региональ дәүләт тикшереп торуын (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләре яисә аларны башкару буенча аерым вәкаләтләр дәүләт учреждениеләренә, муниципаль учреждениеләргә йөкләнгән очракта, «Россия Федерациясендә дәүләт тикшереп торуы (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон белән тикшереп тору (күзәтчелек итү) органнары вәкаләтләренә кертелгән норматив хокукый актларны кабул итү вәкаләтле орган, җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында региональ дәүләт тикшереп торуы (күзәтчелеге) предметы автомобиль юллары һәм юл хуҗалыгы өлкәсендә региональ әһәмияттәге автомобиль юлларына карата билгеләнгән түбәндәге мәҗбүри таләпләрне үтәүдән гыйбарәт:

1) гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының бүленгән полосаларында һәм (яисә) юл буе полосаларында урнашкан юл сервисы объектларын эксплуатацияләүгә карата;

б) автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итү өлешендә гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм алардагы ясалма юл корылмаларын капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм аларны карап тоту эшләрен башкаруга карата (юл-төзелеш материалларына һәм эшләнмәләренә карата таләпләрне дә кертеп).

5. Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль предметы түбәндәге мәҗбүри таләпләрне үтәүдән гыйбарәт:

1) автомобиль юллары һәм юл хуҗалыгы өлкәсендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата билгеләнгән түбәндәге мондый таләпләр:

а) гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының бүленгән полосаларында һәм (яисә) юл буе полосаларында урнашкан юл сервисы объектларын эксплуатацияләүгә карата;

б) автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итү өлешендә гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм алардагы ясалма юл корылмаларын капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм аларны карап тоту эшләрен башкаруга карата (юл-төзелеш материалларына һәм эшләнмәләренә карата таләпләрне дә кертеп);

2) даими ташуларны оештыру өлкәсендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында федераль дәүләт тикшереп торуы (күзәтчелеге) предметына карамаган даими ташуларны муниципаль маршрутлар буенча ташуларга карата.».

2 статья

«Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу турында» 2011 елның 10 октябрендәге 77-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«5 статья. **Җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт тикшереп торуы (күзәтчелеге)**

1. Җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт тикшереп торуы (күзәтчелеге), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган нигезләмәгә таянып, вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт тикшереп торуы (күзәтчелеге) предметы җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хезмәтләрен күрсәтү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан Федераль законның 9 статьясында һәм җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу кагыйдәләрендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне, шулай ук инвалидларның социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктураларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәүдән гыйбарәт.».

3 статья

«Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2018 елның 20 декабрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешнең 3 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 2 өлешнең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендәге вәкаләтләрне башкаруны дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру;».

4 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 04 октябрь
№ 75-ТРЗ

Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 8 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 60 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), түбәндәге эчтәлекле 4^1 өлеш өстәп, үзгәреш кертергә:

«4^1. Никахлашу өйләнешүче затларның теләге буенча тантаналы шартларда башкарылырга мөмкин. Никахлашуны тантаналы шартларда башкару тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.».

2 статья

Әлеге Закон 2021 елның 30 декабреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 04 октябрь
№ 76-ТРЗ

Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» 2004 елның 7 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2011 елның 10 октябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 6; 2011, № 10 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 6 (I өлеш); 2016, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 83 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:

а) 2 өлештә «Федераль законга» сүзләреннән соң «(алга таба – Федераль закон)» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 7 өлеш өстәргә:

«7. Хисап палатасы ведомство бүләкләрен һәм мактау билгеләрен гамәлгә куя ала, бу бүләкләр һәм билгеләр турындагы нигезләмәләрне, аларның тасвирламаларын һәм рәсемнәрен, бүләкләү тәртибен раслый ала.»;

2) 3 статьяда «бәйсезлек» сүзеннән соң «, ачыклык» сүзен өстәргә;

3) 4 статьяның 4 өлешендә «аңа йөкләнгән вәкаләтләрне, шулай ук әлеге Законның 32^1 статьясында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең вәкиллекле органнары белән төзелгән килешүләр нигезендә тапшырылган тышкы муниципаль финанс контроле вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итәрлек санда Хисап палатасы Рәисе тәкъдиме буенча» сүзләрен «, законнар белән йөкләнгән вәкаләтләрне үтәү, Хисап палатасының оештыру һәм функциональ бәйсезлеген тәэмин итү кирәклеген исәпкә алып, Хисап палатасы Рәисе тәкъдиме буенча» сүзләренә алмаштырырга;

4) 5 статьяда:

а) 3 өлештә «бер айдан да» сүзләрен «ике айдан да» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 4^1 өлеш өстәргә:

«4^1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Хисап палатасы Рәисе вазыйфасына кандидатураларның Федераль законда билгеләнгән квалификацион таләпләргә туры килүе турындагы бәяләмәне сорап Россия Федерациясе Хисап палатасына мөрәҗәгать итә.»;

5) 8 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Хисап палатасының Рәисе, Рәис урынбасары һәм аудиторлары вазыйфаларына түбәндәге квалификацион таләпләргә туры килә торган Россия Федерациясе гражданнары билгеләнеп куела:

1) югары белемле;

2) дәүләт идарәсе, муниципаль идарә, дәүләт тикшереп торуы, муниципаль контроль (аудит), икътисад, финанс, юриспруденция өлкәсендә кимендә биш ел эш тәҗрибәсе булган;

3) Россия Федерациясе Конституциясен, федераль законнарны, шул исәптән Россия Федерациясе бюджет законнарын һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы башка норматив хокукый актларны, коррупциягә каршы тору турындагы Россия Федерациясе законнарын, Татарстан Республикасы Конституциясен, вазыйфаи бурычларны үтәүгә кагылышлы Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларны, шулай ук Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары тарафыннан тикшереп тору чараларын һәм эксперт-аналитик чараларны үткәрү өчен тышкы дәүләт аудиты һәм муниципаль аудит (тикшереп тору) стандартларына карата Россия Федерациясе Хисап палатасы раслаган гомуми таләпләрне белгән.»;

6) 10 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктында «"Россия Федерациясе субъектларының контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында" 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

7) 12 статьяга түбәндәге эчтәлекле 1^1 өлеш өстәргә:

«1^1. Әлеге Закон максатларында Хисап палатасы инспекторларына Хисап палатасы аппаратында баш инспектор, әйдәүче инспектор вазыйфаларын, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестры нигезендә идарә башлыгының, бүлек башлыгының ике исемле вазыйфаларын биләүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре керә.»;

8) 13 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13 статья. **Хисап палатасы вәкаләтләре**

1. Хисап палатасы түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетлары акчаларыннан, шулай ук Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда башка акчалардан файдалануның законлылыгын һәм нәтиҗәлелеген тикшереп торуны оештыру һәм гамәлгә ашыру;

2) Татарстан Республикасы бюджеты турындагы закон проектына, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетлары хакындагы законнар проектларына, Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законга һәм Татарстан Республикасы бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетлары хакындагы законнарга үзгәрешләр кертү турындагы законнар проектларына экспертиза ясау, аларның күрсәткечләренең нигезле булуын тикшерү һәм анализлау;

3) Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше, җирле бюджет үтәлеше турындагы еллык хисапны, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетлары үтәлеше хакындагы еллык хисапны тышкы тикшерү;

4) «Дәүләт ихтыяҗлары һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә товарларны, эшләрне һәм хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә аудит үткәрү;

5) Татарстан Республикасы дәүләт милкен булдыруның, мондый милек белән идарә итүнең һәм эш йөртүнең нәтиҗәлелеген бәяләү һәм шушы милекне булдыруның, мондый милек белән идарә итүнең һәм эш йөртүнең билгеләнгән тәртибен үтәүне тикшереп тору (интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә махсус хокукларны да кертеп);

6) Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән салым ташламаларын һәм башка ташламаларны һәм өстенлекләрне, бюджет кредитларын бирүнең нәтиҗәлелеген бәяләү, шулай ук дәүләт гарантияләрен һәм поручительлекләрне бирүнең яисә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге мөлкәт исәбеннән юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан башкарыла торган алыш-бирешләр буенча йөкләмәләрне бүтән ысуллар белән үтәүне тәэмин итүнең законлылыгын бәяләү;

7) законнар проектларына һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының башка норматив хокукый актларына Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләренә кагылышлы өлешендә экспертиза ясау, Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетлары керемнәренең үзгәрүенә китерә торган Татарстан Республикасы законнары проектларына, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт программаларына (Татарстан Республикасы дәүләт программалары проектларына) экспертиза ясау;

8) Татарстан Республикасында бюджет процессын анализлау һәм мониторинглау, шул исәптән бюджет процессында ачыкланган тайпылышларны бетерү һәм Россия Федерациясе бюджет законнарын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

9) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелгән бюджетара трансфертлардан файдалануның законлылыгын һәм нәтиҗәлелеген тикшереп тору, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән очракларда җирле бюджетны тикшерү;

10) Татарстан Республикасы бюджетының, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетларының агымдагы финанс елында үтәлешенә оператив анализ үткәрү һәм үтәлешне оештыруны тикшереп тору, квартал саен Татарстан Республикасы бюджетының, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетларының үтәлеше турында, үткәрелгән тикшереп тору чаралары һәм эксперт-аналитик чаралар нәтиҗәләре хакында Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына мәгълүмат бирү;

11) Татарстан Республикасының дәүләт эчке һәм тышкы бурычының торышын тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

12) Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларында каралган Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше максатларына ирешүнең тормышка ашу мөмкинлекләрен, куркынычларын һәм нәтиҗәләрен Хисап палатасы компетенциясе чикләрендә бәяләү;

13) коррупциягә каршы торуга юнәлдерелгән чараларда вәкаләтләре чикләрендә катнашу;

14) тышкы дәүләт финанс контроле өлкәсендә федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән башка вәкаләтләр.

2. Хисап палатасы, әлеге Законның 32^1 статьясында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең вәкиллекле органнары белән тышкы муниципаль финанс контроле вәкаләтләрен тапшыру турында килешүләр төзелгән очракта, күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

3. Хисап палатасы Федераль законның 6 статьясындагы 11 өлешен гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе вазыйфасына кандидатураларның Федераль законның 7 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән квалификацион таләпләргә туры килүен тикшерүне үткәрү тәртибен билгели.

4. Тышкы дәүләт финанс контроле Хисап палатасы тарафыннан түбәндәгеләргә карата гамәлгә ашырыла:

1) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм дәүләт органнарына, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә һәм унитар предприятиеләренә, шулай ук башка оешмаларга карата, әгәр алар Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге мөлкәттән файдалансалар;

2) җирле үзидарә органнарына һәм Татарстан Республикасында муниципаль органнарга һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм башка федераль законнарда каралган очракларда бүтән затларга карата.»;

9) 15 статьяда:

а) исемендә «һәм муниципаль» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Тикшереп тору чараларын һәм эксперт-аналитик чараларны үткәрү өчен тышкы дәүләт финанс контроле стандартлары Хисап палатасы тарафыннан Россия Федерациясе Хисап палатасы раслаган гомуми таләпләр нигезендә раслана.»;

в) 3 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

10) 16 статьяда:

а) 2 өлештә «һәм гарызнамәләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы йөкләмәләре Хисап палатасы Коллегиясе карары белән аларның кергән көненнән алып 10 көнлек срокта Хисап палатасы эшчәнлегенең еллык планына кертелә.»;

11) 19 статьяга түбәндәге эчтәлекле 2^1 өлеш өстәргә:

«2^1. Тикшерелә торган органнарның һәм оешмаларның җитәкчеләре тикшереп тору чараларында катнашучы Хисап палатасының тиешле вазыйфаи затларын белешмә хокук системаларыннан, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдалана алу мөмкинлеге белән җиһазландырылган эш урыны белән тәэмин итәргә тиеш.»;

12) 20 статьяда:

а) 1 өлештә «хокуклы булган» сүзләреннән соң «яисә тышкы дәүләт финанс контролен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматка ия булган» сүзләрен өстәргә;

б) 2 өлештә «һәм гарызнамәләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 10 өлеш өстәргә:

«10. Тышкы дәүләт финанс контроле гамәлгә ашырылганда мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүматны яклау турындагы Россия Федерациясе законнары, дәүләт сере һәм закон белән саклана торган башка сер хакындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә Хисап палатасына аның вәкаләтләрен башкару өчен кирәкле булган дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларыннан даими файдалана алу мөмкинлеге бирелә.»;

13) 21 статьяда:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы бюджетының һәм Татарстан Республикасы бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетларының үтәлешенә оператив анализ һәм аларның үтәлешен оештыруны тикшереп тору»;

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Хисап палатасы Татарстан Республикасы бюджетын, Татарстан Республикасының бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетларын үтәү барышында керемнәрнең тулысынча һәм вакытында керүен, Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законның, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетлары хакындагы законнарның расланган күрсәткечләре белән чагыштырганда бюджет чыгымнары һәм кытлыкларны финанслау чыганаклары үтәлешен анализлый, тайпылышларны һәм хокук бозуларны ачыклый, аларга анализ үткәрә, аларны бетерү буенча тәкъдимнәр кертә.»;

в) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы бюджетының һәм Татарстан Республикасы бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетларының агымдагы финанс елында үтәлешен оператив анализлау һәм аларның үтәлешен оештыруны тикшереп тору белешмәләре тикшереп тору чараларын һәм эксперт-аналитик чараларны планлаштырганда файдаланыла.»;

14) 25 статьяда:

а) 1 өлештә «карау һәм» сүзләрен төшереп калдырырга, «ачыкланган» сүзеннән соң «бюджет хокук бозуларын һәм кимчелекләрен, башка» сүзләрен өстәргә;

б) 3 өлештә «тәкъдимне алган көннән бер ай эчендә» сүзләрен «тәкъдимдә күрсәтелгән срокта яисә, срогы күрсәтелмәгән булса, аны алган көннән алып 30 көн эчендә» сүзләренә, «тәкъдимне карау» сүзләрен «тәкъдимне үтәү» сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 3^1 өлеш өстәргә:

«3^1. Тәкъдимне үтәү срогы Хисап палатасы карары белән озайтылырга мөмкин, әмма бер тапкырдан да артыкка түгел.»;

г) 4 өлештә «хокук бозулар ачыкланган» сүзләреннән соң «, Хисап палатасы күрсәтмәләре үтәлмәгән» сүзләрен өстәргә;

д) 6 өлештә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Күрсәтмәне үтәү срогы Хисап палатасы карары белән озайтылырга мөмкин, әмма бер тапкырдан да артыкка түгел.»;

е) 7 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Хисап палатасы тәкъдимен яисә күрсәтмәсен үтәмәү Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән җаваплылыкка китерә.»;

15) 26 статьяның 1 өлешендә:

а) 1 пунктта «, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законга һәм Татарстан Республикасы бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетлары хакындагы законнарга үзгәрешләр кертү турындагы законнар проектларына» сүзләрен өстәргә;

б) 3 һәм 4 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) законнар проектларына һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының башка норматив хокукый актларына Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләренә кагылышлы өлешендә, Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетлары керемнәренең үзгәрүенә китерә торган Татарстан Республикасы законнары проектларына;

4) Татарстан Республикасы дәүләт программаларына (Татарстан Республикасы дәүләт программалары проектларына);»;

16) 31 статьяда:

а) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Хисап палатасының вазыйфаи затларына ел саен түләүле отпусклар (төп һәм өстәмә), һөнәри үсеш, шул исәптән өстәмә һөнәри белем алу, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар өчен билгеләнгән башка матди һәм социаль тәэминат чаралары (шул исәптән, медицина һәм шифаханә-курорт тәэминаты, көнкүреш, транспорт буенча хезмәт күрсәтү һәм хезмәт күрсәтүнең бүтән төрләре буенча) гарантияләнә.»;

б) 7 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

17) 32 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле 1^1 өлеш өстәргә:

«1^1. Хисап палатасы хезмәттәшлек һәм үзара эшләү турында төзелгән килешүләр нигезендә тикшереп тору чараларын һәм эксперт-аналитик чараларны үткәрүдә катнашуга тикшереп тору, хокук саклау органнарын һәм башка органнарны, аларның вәкилләрен, шулай ук шартнамә нигезендә аудитор, фәнни-тикшеренү, эксперт учреждениеләрен, оешмаларын һәм башка учреждениеләрне, оешмаларны, аерым белгечләрне, экспертларны, тәрҗемәчеләрне җәлеп итәргә хокуклы.»;

б) 6 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6) муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары мөрәҗәгатьләре буенча муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе вазыйфасына кандидатураларның Федераль законда билгеләнгән таләпләргә туры килүе турындагы бәяләмәләр бирергә.»;

в) түбәндәге эчтәлекле 7 өлеш өстәргә:

«7. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы яисә Хисап палатасы аның эшчәнлегенең тышкы дәүләт финанс контроле турындагы законнарга туры килүе хакындагы бәяләмәне һәм Хисап палатасы эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәрне сорап Россия Федерациясе Хисап палатасына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.».

2 статья

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 2; 2010, № 1 – 2; 2011, № 5; 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш), «муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисенә дә, шулай ук муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе урынбасарына һәм аудиторына, әгәр күрсәтелгән вазыйфалар билгеләнгән тәртиптә муниципаль вазыйфаларга кертелгән булса,» сүзләрен «шулай ук муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисенә, рәисе урынбасарына һәм аудиторына да» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

3 статья

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең аерым мәсьәләләре турында» 2012 елның 17 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 5 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 4 статьяда:

а) 1 өлештә «Федераль закон» сүзләрен «федераль законнар» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «һәм гарызнамәләре» сүзләрен төшереп калдырырга.

4 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 04 октябрь
№ 77-ТРЗ

КОТЛЫЙБЫЗ!

Илебездә спортны үстерүгә зур өлеш кертүе, Токио шәһәрендә (Япония) 2020 елгы XXXII Олимпиада Уеннарында югары спорт күрсәткечләренә ирешкәне өчен «Россия җыелма командаларына спорт әзерлеге бирү үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Россия Федерациясенең фехтование буенча җыелма спорт командасы спортчы-инструкторы, «Фехтование буенча олимпия резервы республика спорт мәктәбе» дәүләт автоном учреждениесе спортчы-инструкторы **Мартьянова** Марта Валерьевна **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

***

Илебездә спортны үстерүгә зур өлеш кертүе, Токио шәһәрендә (Япония) 2020 елгы XXXII Олимпиада Уеннарында югары спорт күрсәткечләренә ирешкәне өчен «Зенит» волейбол клубы» (Казан шәһәре) автоном коммерциячел булмаган оешмасының спортчы-инструкторы **Михайлов** Максим Михайлович **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Токио шәһәрендә (Япония) 2020 елгы XXXII Олимпиада Уеннарында югары спорт күрсәткечләренә ирешкәне өчен «Зенит» волейбол клубы» (Казан шәһәре) автоном коммерциячел булмаган оешмасының спортчы-инструкторы **Вольвич** Артем Александрович; «Зенит» волейбол клубы» (Казан шәһәре) автоном коммерциячел булмаган оешмасының спортчы-инструкторы **Голубев** Валентин Андреевич; «Россия җыелма командаларына спорт әзерлеге бирү үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Россия Федерациясенең йөзү буенча җыелма спорт командасы спортчы-инструкторы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының «Спорт әзерлеге үзәге» дәүләт автоном учреждениесенең спортның җәйге төрләре бүлеге спортчы-инструкторы **Красных** Александр Владимирович; һөнәри вазыйфаларын үтәгәндә күрсәткән шәхси батырлыклары һәм кыюлыклары өчен Казан шәһәре Совет районының «175 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе хезмәткәрләре: рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Бохараева** Алинә Дамир кызы; туган тел һәм туган әдәбият укытучысы **Галиуллина** Диларә Әхмәдулла кызы; математика укытучысы **Гафурова** Альмира Әнвәр кызы; башлангыч сыйныфлар укытучысы **Гаязова** Энҗе Фәргать кызы; инглиз теле укытучысы **Гыйльмуллина** Динә Дилбәр кызы; рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Гузенфельд** Роман Львович; туган тел һәм туган әдәбият укытучысы **Зарипова** Алинә Әнис кызы; физик культура укытучысы **Лекомцев** Даниил Фёдорович; математика укытучысы **Поликарпова** Анастасия Владимировна; биология укытучысы **Пономарева** Алла Борисовна; инглиз теле укытучысы **Сабирҗанова** Алия Илдар кызы; физик культура укытучысы **Сабиров** Рамил Габделфәрт улы; физик культура укытучысы **Смелов** Руслан Александрович; туган тел һәм туган әдәбият укытучысы **Хәкимова** Мәдинә Сәгыйдулла кызы; директорның уку-укыту эше буенча урынбасары **Халикова** Венера Закирҗан кызы; башлангыч сыйныфлар укытучысы **Хәлиуллина** Эльмира Фәрит кызы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Токио шәһәрендә (Япония) 2020 елгы XXXII Олимпиада Уеннарында спортчыларның югары күрсәткечләргә ирешүенә зур өлеш кертүләре өчен Россиянең атказанган тренеры **Алекно** Владимир Романович; «Спорт резервын әзерләү федераль үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең фехтование буенча Россия Федерациясе җыелма спорт командасы тренеры (Мәскәү шәһәре) **Әхмәтхуҗин** Артур Камил улы; Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының «Спорт әзерлеге үзәге» дәүләт автоном учреждениесенең спортның җәйге төрләре бүлеге тренеры **Кузнецов** Алексей Александрович; Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының «Спорт әзерлеге үзәге» дәүләт автоном учреждениесенең спортның җәйге төрләре бүлеге баш тренеры **Тарасов** Сергей Юрьевич; «Фехтование буенча олимпия резервы республика спорт мәктәбе» дәүләт автоном учреждениесе директоры **Шәймәрданов** Илдар Равил улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының югары казанышлар спортын үстерү бүлеге башлыгы **Вафин** Раиф Ришад улына; Казан шәһәренең «Смена» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тренеры **Миңнекаев** Альберт Фәйдехан улына; Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «Яшьлек» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тренеры **Миңнуллин** Рафис Хасип улына; «Динамо» олимпия резервы республика спорт мәктәбе» дәүләт автоном учреждениесе тренеры **Мирасов** Тимур Әсбүхан улына; «Татарстан Республикасының фехтование федерациясе» төбәк спорт иҗтимагый оешмасы әгъзасы **Прохорова** Елена Александровнага **«Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

ФИНАНС МИНИСТРЫ РАДИК ГАЙЗАТУЛЛИН:

«БЮДЖЕТНЫҢ ҺӘР ТИЕНЕ ИСӘПТӘ»

Татарстан Президенты республика парламентына бюджет юлламасын кертте. Республиканың төп финанс документы ничек эшләнгән, бюджет сәясәтендә нинди яңалыклар бар? Татарстан Республикасы финанс министры Радик ГАЙЗАТУЛЛИНга «ВТ» хәбәрчесе әнә шундыйрак сораулар белән мөрәҗәгать итте.

:: Радик Рәүфович, 2022 елга һәм пландагы чорга бюджет республиканың сезнең җитәкчелектә әзерләнелгән егерменче бюджеты булып тора. Гаять зур белем-тәҗрибәгездән чыгып, яңа әзерләнгән документны ничегрәк бәяләр идегез?

– Бу хакта искә төшерүегез өчен рәхмәт. Гомумән алганда, соңгы ике дистә вакыт эчендә республика икътисады ныгыды һәм ыргылышлы төстә үсте. Әмма бу юл җиңел генә булмады. Без даими рәвештә иң яхшы чишелешләр эзләп табарга тырышабыз. Бюджет «язмышы» аша республиканың тарихын өйрәнергә мөмкин. Шушы вакыт эчендә 2010 елгы корылыкны, 2009, 2014 һәм 2020 еллардагы кризисларны, Бюджет кодексының тулысынча яңартылуын, җирле үзидарәнең, озак вакытка исәпләнелгән планлаштырылуның гамәлгә кертелүен, бюджет оешмаларының хокукый хәленең камилләштерелүен, пандемияне һәм аның аянычлы нәтиҗәләрен кичердек, дөнья күләмендәге төрле сәяси һәм спорт чаралары үткәрдек.

Безнең республика үсешнең яңа баскычына күтәрелде, халыкның тормышы яхшырды, башкалабызны бөтен дөнья таный башлады. Бу чараларның барысы да республика җитәкчелегенең төптән уйланылган сәясәте нигезендә тормышка ашырылды һәм, һичшиксез, бюджетта чагылдырылды. Икътисадта кыенлыклар килеп туганда, уртак рәвештә төрле яклап уйланылган карарлар кабул ителә. Мәсәлән, 2009 елда капиталь чыгымнарны туктатып тордык, тотрыклылык пәйда булгач, алар торгызылды. Бюджет чыгымнары киметелде. Узган елда, бөтен дөнья COVID-19 инфекциясе таралуга бәйле кыенлыкларны кичергән бер мәлдә дә, шушы тәҗрибә кулланылды. Кече һәм урта бизнеска ярдәм итү буенча төрле чаралар күрелә.

Киләсе елга бюджет, алдагы еллардагы кебек үк, агымдагы бюджетның үтәлешенә, көтелә торган ел йомгакларына, Россия Федерациясе Икътисад министрлыгының сценарий шартларына һәм 2022–2024 елларга Татарстан Республикасы социаль-икътисади үсешенең төп күрсәткечләренә нигезләнә. Федераль законнарга ел саен кертелә торган үзгәрешләр, бер яктан, бюджетыбызның керемнәрен киметә, икенче яктан, чыгым өлешен арттыра. Нәтиҗәдә республика бюджетына авырлык килә. Әнә шундый катлаулы шартларда алдагы 3 елга бюджет төзедек.

:: Мәгълүм булганча, бюджетны төзү аның керем өлешен булдырудан башланып китә. Ничегрәк ул?

– Бюджет керемнәренә килгәндә, аның буенча эшләр инде язын ук башлана. Аерым керем чыганаклары күләмнәре тәгаенләнә, хуҗалыклар һәм муниципаль берәмлекләр, предприятиеләр вәкилләре, Икътисад министрлыгы, салым хезмәте, шулай ук тармак министрлыклары белгечләре белән финанс-хуҗалык эшчәнлеге мәсьәләләре карала. Бюджетка керергә тиешле һәрбер сум бик күп исәп-хисапларга нигезләнелә һәм җентекләп фаразланыла.

Татарстанның бюджет системасы 45 район һәм шәһәр бюджетын үз эченә ала. Республиканың төп финанс документын булдыру барышында муниципаль берәмлекләр вәкилләре белән бик тыгыз элемтәдә эшләдек. Аларның җирле бюджетларның керем өлешен булдыру буенча тәкъдимнәрен карадык. Нәтиҗәдә җирле бюджетларның кереме күләме буенча фаразлар муниципалитетлар белән бернинди каршылыксыз килештерелде.

Бюджет керемнәре арасында табышка салым, физик затлар керемена салым, акцизлар, оешмалар милкенә салым төп керемнәр булып тора. 2022 елга

тупланма бюджетның салым һәм салым булмаган керемнәренең гомуми күләме – 296,8 миллиард сум, 2023 елга – 306,4 миллиард сум, 2024 елга 318,0 миллиард сум күләмендә фаразланыла.

:: Киләсе елга республика бюджеты чыгымнарының үзенчәлекләре турында сөйләп үтсәгез иде. Капиталь чыгымнарның күләмнәре кимемәсме?

– Беренче чиратта кирәкле һәм социаль әһәмиятле чыгымнар күләме саклап калачак. 2022 елга төзелгән бюджетта алар чыгымнарның гомуми күләменең 79 процентын тәшкил итәчәк. Чыгымнарда бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең аерым бер категорияләренең хезмәт хакын икътисадта уртача хезмәт хакына җиткерү өчен акча күздә тотылган, шулай ук хезмәткә түләүнең минималь күләмен арттыру исәпкә алынган. Социаль сәясәткә чыгымнарның гомуми күләме – 44,6 миллиард сум, шул исәптән социаль түләүләр 21,5 миллиард сум күләмендә фаразланыла. Соңгы 3 елда социаль түләүләр шактый ук үсте. Аларның күләме 65 процентка артты.

Шуны басым ясап әйтәсем килә: алдагы елларда башланган социаль-мәдәни өлкә һәм иҗтимагый инфраструктура объектларын төзүне, капиталь төзекләндерүне финанслау дәвам итәчәк. Шулай ук республикада берничә ел дәвамында гамәлдә булып килүче социаль әһәмиятле чараларны финанслау күздә тотылган.

2022 елга, федераль средстволарны исәпкә алмыйча, тупланма бюджетның чыгым өлеше 307,7 миллиард сум күләмендә, 2023 елга – 319,1 миллиард сум, 2024 елга 323,0 миллиард сум күләмендә фаразланыла.

:: Бюджетны төзү барышында җирле органнар белән хезмәттәшлек алып барыламы? Алар нинди йогынты ясый?

– Республиканың бюджет системасы өчен төбәкләр бюджетлары белән иңгә-иң торып эшләү гаять зур әһәмияткә ия. Биредә барлык дәрәҗәләрдәге бюджетларның мөстәкыйльлеге мөһим. Шул ук вакытта республикада барыбыз да – дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары да, җирле үзидарә органнары да шуны яхшы аңлыйбыз: бюджет сәясәте һәм бюджет дисциплинасы барыбыз өчен дә бердәм булырга тиеш. Барлык дәрәҗәләрдәге бюджетларны уңышлы үтәүнең нигезе – бердәм кагыйдәләрне үтәү. Кем әйтмешли, бердәмлектә – көч!

Ай саен муниципалитетлар вәкилләре белән үткәрелә торган киңәшмәләрдә җирле бюджетларның агымдагы үтәлеше карала, Президент катнашында һәр квартал саен йомгак ясала, хәл кылуны таләп иткән мәсьәләләр вакытында өйрәнелә. Күпләрдә акчаны керемнәр мөмкинлек биргәннән күбрәк тоту теләге бар. Бюджетны эшләү мәсьәләсе буенча очрашуларда төбәкләрнең сценарий шартларына сыешмаган тәкъдимнәре каралды. Бу тәкъдимнәр гомумиләштерелде. Алар бюджетны үтәү барышында, өстәмә алынган керемнәр, бюджеттан тыш эшчәнлектән керемнәр, чыгымнарны экономияләү хисабына, тормышка ашырылырга мөмкин.

:: Булачак бюджетның нигезенә аның агымдагы үтәлеше салына, дидегез. Бүгенгә республика бюджеты ничегрәк үтәлә?

– Агымдагы елның 9 аенда республика бюджеты шактый ук уңышлы үтәлеп килә. Планда каралган барлык чаралар хәл ителә. Керемнәр асылда көтелгәнчә алына, бу, үз чиратында, бюджетның чыгым өлешен үтәү мөмкинлеге бирә.

Хисап мәгълүматларына караганда, агымдагы елның 9 аенда Татарстан Республикасы тупланма бюджетына 232,5 миллиард сум күләмендә салым һәм салым булмаган керемнәр кергән.

Планда каралган барлык чыгымнар финансланыла. Бюджет өлкәсендә эшләүчеләргә хезмәт хакы үз вакытында түләнеп килә, социаль түләүләр һәм пособиеләр индексацияләнә, бюджет оешмаларының коммуналь хезмәтләренә түләнелә, илкүләм проектлар финансланыла, инвестиция программалары тормышка ашырыла.

:: 4 октябрьдә Президент Дәүләт Советына бюджет Юлламасын кертте. Алга таба бюджет буенча эш ничегрәк дәвам итәчәк? Аны кабул итү кайчанга планлаштырыла?

– 6 октябрьдә депутатлар, җирле үзидарә органнары вәкилләре катнашында Татарстан Республикасы тупланма бюджеты проекты буенча фикер алышуга бәйле зона киңәшмәсе үткәрелә. 11 октябрьдә парламент тыңлаулары була: анда закон проекты җәмәгатьчелек вәкилләре катнашында тикшереләчәк. Теләгендә булган барча кешене әлеге чарада катнашырга чакырабыз. 15 октябрьгә кадәр бюджетны Дәүләт Советы комитетларында карау һәм 25 октябрьдә парламент утырышына I укылышта кабул итүгә кертү күздә тотыла. Ноябрь аенда исә яңа бюджетны кабул итү планлаштырыла.

Сүз уңаеннан, бюджет мәсьәләләре белән даими кызыксынган өчен «Ватаным Татарстан» газетасына һәм аны укучыларга рәхмәт әйтәсем килә.

ӘЛЕ КИРӘК, ӘЛЕ КИРӘКМИ...

Яшәеш

Базар шартлары да авыл кешесен җил искән якка карап эшләргә өйрәтә бугай. Алай дисәң, җилнең кайсы якка борылганын һич тә чамалап бетерә торган түгел шул. Әйтик, бүген бәрәңге кирәк түгел, иртәгә ит сатып алучы калмый... Ә берәздан икесе дә бик үтемле товарга әйләнә.

Шунысы гына бар: базарда сорау артты дип кенә аны көне-сәгате белән җитештереп булмый. Әнә быел бәрәңге бөтен кешегә дә кирәк, тик хуҗалыклар аңа кул селтәде шул инде. «Тукта, бәлки» дип сабыр иткәннәр генә отты быел. Быел отты, киләсе елга нәрсә буласын барыбер белеп булмый. Бәрәңгегә бәянең кайчан ничек буласын да фаразлап булмый. «Көзен сатып бетермик әле, язга бәя артыр дип калдырсаң, язын бәяләр, киресенчә, төшә, ә сатып бетерсәң, язга инде бермә-бер арта да, тагын отылдым дип, күңел көенә», – дигән иде бәрәңге үстерү белән заманында чын-чыннан шөгыльләнеп, соңгы елларда кул селтәгән хуҗалык җитәкчесе. Кошчылык белән шөгыльләнүче бер фермер да: «Чеби ул такта түгел, аны өеп куеп булмый», – дигән иде. Нәкъ шуның кебек, авыл хуҗалыгындагы күп продукцияне складларга өеп куеп, бәясе артканын көтеп тору мөмкин түгел.

Шуңа да, заманга ияреп, кирәклесен, үтемлесен үстерергә, игәргә тырыша авыл кешесе. Файдалысын, табышлысын эзли. Шул ук вакытта экспериментлар ясамыйча, яңалыкларга тотынмыйча да булмый. Бер чорда бөртеклеләргә, сабан культураларына өстенлек бирелсә, хәзер аларның көзге төрләре (чөнки соңгы елларда уңыш белән нәкъ менә көзге культуралар «терәде») һәм терлек азыгы культуралары мәйданнарын арттыралар, кайчандыр кул селтәгән рапска, кукурузга кабат әйләнеп кайттылар. Дөрес, кукуруз элекке ил башлыгы Никита Хрущев заманыннан бирле игелә. Тик... хәзер инде ул бөтенләй яңача үстерелә. Чорына карап, аңа мөнәсәбәтләр төрле булса да, соңгы елларда ул кабат пьедесталның иң биек баскычына күтәрелде. Үзенең энергияле азык чыганагы булуын кабат раслады. Үткән гасырның илленче еллар азагы –

pixabay.com

алтмышынчы еллар башында аңа булган мөнәсәбәт еш кына мәзәк хәлләргә чыганак булса да, бүген ул бөтенләй башка яктан – орлыкка җитештерү юнәлеше буенча популярлаша бара. Безнең Балтач районында бу юнәлеш белән биш-алты еллап нәтиҗәле эшләүче хуҗалыклар бар. Сыттырып, җиңсәләргә дә тутыралар, орлыгын киптерәләр дә. Силосын да бик мулдан, яхшы сыйфатлы итеп әзерлиләр, карнаж ясаучы хуҗалык та бар. Шунысы да кызык: кукурузны гомер-гомергә иң азактан, җылы ярата торган культура дип, май ахыры – июнь башында чәчәләр иде. Хәзер киресенчә... Майда була торган кыраулардан курка-курка булса да, иртә чәчәләр. Үсү, орлыгының өлгерү срогы бар, аңа сыешу өчен иртә чәчәргә, майның кояшлы көннәрендә үсеп калуы кирәк, майның шундый бер көне августның биш көненә тора, диләр. Бөтенләй башка сортлар, башка технология белән эшлиләр. Яңадан-яңа сортлар, гибридлар барлыкка килгән. Алай гына да түгел, «...бу базарда конкуренция бик көчле, һәркем үзенең товарын тәкъдим итәргә тырыша. Шуңа күрә үзебезнең шартларга яраклы, алданрак өлгерә торган, табышлы, файдалы сортларны сайлап ала белү бик мөһим, шулай ук үстерү технологиясен дә төгәл үтәргә кирәк. Кукуруз бик нәзберек культура димәс идем. Шулай да ул туфракка зур игътибар сорый. Без инде киләсе елга кукуруз үстерәсе мәйданнарны көздән үк тәгаенләп, тирәнәйтеп эшкәртеп, туфрагын анализга җибәрәбез. Чәчтең дә үстердең генә түгел... Бездә инде аны орлыкка үстерергә өйрәнеп җиттеләр, шул сәбәпле кукуруз мәйданнары елдан-ел арта. 50 гектар мәйданнан башлаган идек, быел 700 гектарда үстердек, киләсе елга 1000 гектарга җиткерергә исәп. Коры елда да орлыкка уңышын арпа белән чагыштырганда бермә-бер артык алдык», – ди бу юнәлештә 2016 елдан бирле уңышлы эшләүче хуҗалык җитәкчесе Фердинанд Хәйруллин.

Менә шулай: бу сезонда бәрәңге һәм кукуруз кыр патшаларына әйләнде. Озаккадырмы, монысын әлегә фаразлап булмый. Базар «җил»е кая таба исә бит...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Көрәш федерациясе Президиумы, Татарстан Республикасы Көрәш федерациясе төбәк иҗтимагый оешмасы башкарма директоры
Равил Гарифулла улы ХӘЙРУЛЛИНның
вакытсыз вафат булуы сәбәпле, аның гаиләсенең һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.
Равил Гарифулла улының якты рухы безнең күңелләрдә мәңге сакланыр. Якыннарына әлеге олы кайгыны күтәрү өчен күркәм сабырлык телибез.

«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе, Татарстан Республикасы Көрәш федерациясе төбәк иҗтимагый оешмасы башкарма директоры
Равил Гарифулла улы ХӘЙРУЛЛИНның
вакытсыз вафат булуы сәбәпле, аның гаиләсенең һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.
Равил Гарифулла улы озак еллар «Ватаным Татарстан» газетасының герой-шагыйрь М.Җәлил истәлегенә уздырылучы көрәш турнирларының алыштыргысыз оештыручыларының берсе булды. Безнең күңелләрдә ул тәҗрибәле җитәкче, тынгысыз оештыручы, татар җанлы шәхес булып сакланыр.

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе, «Татарстан Республикасы көрәш федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы башкаручы директоры, Балык Бистәсе районы элекке хакимияте башлыгы (1998–2005 елларда)
ХӘЙРУЛЛИН Равил Гарифулла улының
гомере вакытсыз өзелү сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

ФГБУ «ЦАС «Татарский» коллективы һәм җитәкчесе Әнәс Локманов,
ХӘЙРУЛЛИН Равил Гарифулла улы
вафат булу сәбәпле, туганнарының авыр кайгысын уртаклаша.

«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе коллективы, әтисе
ФАТЫХОВ Камил Шаһи улының
вафат булуы сәбәпле, редакция хезмәткәре – корректор Минһаҗева Илүсә Камил кызының, гаиләсенең, туганнарының авыр кайгысын уртаклаша.

Белдерү

Кадастровым инженером Биктимировым Ильшатом Ринатовичем (почтовый адрес: 420100, г. Казань, ул. 2-ая Азинская, д. 1, контактный тел.: 89600482408, электронная почта biktimirov_i@mail.ru, № квалификационного аттестата 16-10-80) в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:50:240621:152, расположенного по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Советский район, сдт «Чишма», участок 96, выполняются кадастровые работы по уточнению границ земельного участка.

Заказчиком кадастровых работ является Шаяхметов Газинур Анасович (почтовый адрес: Республика Татарстан, г. Казань ул. Заботина, д. 34).

С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться в будние дни с 9.00 до 17.00 ч. по адресу: 420100, г. Казань, 2-ая Азинская, д. 1.

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ земельного участка состоится по адресу: 420100, г. Казань, 2-ая Азинская, д. 1 8 ноября 2021 года в 10 часов 00 минут.

Возражения по проекту межевого плана и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются со дня опубликования в печатном издании в течение месяца по адресу: 420100, г. Казань, 2-ая Азинская, д. 1.

Смежный земельный участок, с правообладателем которого требуется согласовать местоположение границы земельного участка: 16:50:240621:153.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок.

ИЗВЕЩЕНИЕ О НЕОБХОДИМОСТИ СОГЛАСОВАНИЯ ГРАНИЦ ЗЕМЕЛЬНОГО УЧАСТКА

Кадастровым инженером Катиным Сергеем Вячеславовичем (аттестат 16-11-169, адрес: 420138, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Дубравная, д. 51Г, офис 1, тел.: (917) 850-99-44) в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:50:300303:122, расположенного по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Кировский район, СДТ «Залесный», уч. №1, выполняются кадастровые работы по уточнению местоположения границ и площади данного земельного участка.

Заказчик: Хабибрахманов Инсаф Илхамович (адрес: Респ. Татарстан, г. Казань, ул. Нурихана Фаттаха, д. 15, кв. 90, тел.: +79377742024).

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ состоится 10 ноября 2021 г. в 09 часов 00 минут по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Дубравная, д. 51Г, офис 1.

Ознакомиться с проектом межевого плана и предъявить обоснованные возражения относительно местоположения границ земельного участка можно по адресу: 420138, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Дубравная, д. 51Г, офис 1 в течение 30 (тридцати) дней со дня выхода данного извещения в печать.

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границ: 16:50:300303:118, 16:50:300303:123, 16:50:300303:228, расположены в границах кадастрового квартала 16:50:300303, Республика Татарстан, г. Казань, Кировский район, СДТ «Залесный».

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы, подтверждающие права на соответствующий земельный участок.

Шөгыль

Пенсиягә чыккач, яңа тормыш башлана

Замана өлкәннәре әнә шулай ди. Лаеклы ялга чыктым дип кенә берсенең дә өйдә утырасы килми. Алай гына да түгел, пенсиягә чыккач, яңа һөнәр үзләштерүчеләр дә шактый. Кемдер тегүчелеккә укый, кемдер косметолог һөнәрен үзләштерә. Икешәр эштә эшләүчеләр дә бар.

Казанда яшәүче Рузилә Шәйдуллинага 57 яшь. Тиешле еллар эшләгән өчен күптән пенсиядә булса, быел лаеклы ялга да чыккан. Әмма укытучы булып эшләвен дәвам итә әле.

– Мәктәпләрдә укытучылар җитеп бетми. Быел 1 нче сыйныфларны алырга туры килде. Мәскәү районының 34 нче мәктәбендә башлангыч сыйныфларны укытам. Эшем дә бик ошый. Әмма киләчәкне уйладым. Эштән китсәм, хәзер яңа һөнәрем бар. Косметологка укыдым, – ди ул.

Рузилә Шәйдуллина, пенсиягә чыккач, косметолог һөнәрен үзләштергән. Хәзер: «Матурлык үз кулымда, картаерга вакытым да юк», – дип шаярта.

Рузилә Шәйдуллина, пенсионерларны укытабыз, дигән сүзне ишетүгә, бик теләп риза була. Хәер, үзе әйтмешли, беренче тапкыр гына укуы түгел икән инде. Ул гомере буе яңа белемгә омтыла. Күптән түгел психологка да укып чыккан, тик косметология күбрәк ошаган.

– Безне Халыкара сервис көллиятендә укыттылар. Андагы укытучыларга чиксез рәхмәтлемен. Үзләренең җәйге яллары вакытында безгә белем бирделәр. Үземне алар урынына куям да сабырлыкларына шаккатам, – ди Рузилә ханым. – Гомер буе башка эшкә өйрәнгән кешеләр бит без. Кулларыбыз берни тотмый иде. Тыныч кына барысын да өйрәттеләр, күрсәттеләр. Массаж, бизәндерү, биткә маскалар кую, кашны матурлау, керфекләрне үстерү буенча күп кенә дәресләр бирделәр. Хәзер инде эшли беләм. Үзем дә гел матур йөрим. Якыннарым да, дусларым да миңа киләләр. Укытучылыгымны ташларга җыенмыйм, буш вакытым бар, шунда эшләячәкмен. Үзмәшгуль булып та теркәлдем. Матурлык үз кулымда, картаерга вакытым юк.

Бөгелмә шәһәрендә яшәүче Наталья Горбачева да элек балаларны математикадан укыткан. Пенсиядә бераз гына ял итеп алган да яңа һөнәр үзләштергән. Ул хәзер – тегүче.

– Мәктәптә 37 ел эшләдем. Шөкер, пенсиям аз түгел. Әмма тормыш авыр. Акчасыз бернишләп булмый хәзер. Шуңа да мул тормышта яшәр өчен, пенсиягә генә карап утырып булмый, тегү тегәм, – ди ул. – Элек тә бераз теккәли идем. Әмма осталыгым булмады. Көллияттә укыганда безне бик яхшы итеп өйрәттеләр. Тегүнең дә үз серләре бар икән. Бу эшкә тиз өйрәндем. Бөтен гаиләмә, якыннарыма нәрсә кирәк, шуны тегеп бирәм.

Наталья ханым да картлык сүзен яратмый. Пенсиягә чыккач, яши генә башладым әле мин, ди ул. Үзе әйтмешли, элек бар гомере мәктәптә узса, хәзер оныклар да караша, кул эшләренә дә вакыты кала. Чигә дә, бәйли дә.

– Пенсиягә алдан әзерләндем. Кайберәүләр, эштән киткәч, кеше үз эченә бикләнә, күңелсезләнә, картая, дигән иде. Икенче һөнәр алу бар дөньямны үзгәртте. Мин үземне башка яктан ачтым. Тегү теккәндә күңел тынычлана, рәхәт. Мәктәп бөтен тормышымны урлый иде. Тегүне кайчан тексәң дә була. Дусларыма да вакыт табам, табигатькә дә чыгабыз. Йөрәк гел яшь әле, картаясым килми. Хәер, дәүләт мөмкинлеген биреп, безне кайгыртып торганда, картлык та килми тора кебек. Көннең ничек узып киткәнен дә сизмим, – ди ул.

Наталья ханым, гел яхшы уйлар белән яшим, ди:

– Беркайчан да моңаеп утырмадым. Борчулар да, хәсрәтләр дә бар инде ул. Әмма үзеңне кулга алырга, тыныч тотарга кирәк. Киләчәккә зур планнар белән яшим. Үзмәшгуль булып теркәлеп эшлисем килә. Әлегә заказлар кабул итәм. Бу көннәрдә үземә җылы спорт киеме тегеп утырам әле. Ошаса, башкаларга да тегәрмен дип торам. Тегү машинам совет чорыныкы. Кул белән тегәргә кирәк. Әмма бик яхшы эшли. Минем өчен хәзер иң мөһиме шул. Үзем авырмасам, машинам ватылмаса, бар да яхшы булачак.

50 яшь һәм аннан да өлкәнрәкләр «Демография» илкүләм проекты кысасында укытыла. Аның нигезендә 2019 елда – 4747 кеше, 2020 елда 3501 кеше икенче һөнәр алган. 2021 елда 2145 кешене өстәмә белем алырга җибәргәннәр. Өлкәннәр күбрәк сакчы, пешекче, кондитер, котельный операторы кебек һөнәрләрне сайлый. 50 яшькә җиткән кеше икенче һөнәр алырга тели икән, мәшгульлек үзәгенә барып теркәлергә тиеш. Укыту – бушлай.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ӘЙДӘ, АВЫЛГА КАЙТЫЙК!

ЯШӘҮЧЕДӘ ЯШӘҮ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

Чирмешән районының Яшәүче авылы бетү түгел, яшәү турында уйлый. Йортлар саны утыздан артык кына булса да, халкы мондагы рухны сүндермәскә тырыша. Шәл бәйләүчеләре, бавырсак пешерүчеләре белән дан тота ул. Әлеге авылга багышланган биш җыр гына бар! Монда соңгы елларда Сабантуйлар, Авыл көннәренең узмыйча калганы юк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Клубы бар, кибете юк...

Элек авылда 74 йорт булган, хәзер 34кә генә калган. Авылда 69 кеше яши. Халкы нигездә бер урамда яшәгән җыйнак кына авыл бу. Әрдәнәгә өелгән утын өемнәрен, авыл башындагы көтүне күргәч, элеккеге авыл күз алдына килә. Тик көтүне электрон көтүче көтә икән. Казлар каңгылдаша, бәрәннәр кычкыра... Авылны иман нурына төреп, азан яңгырый. Димәк, яшәргә күңелсез түгел әле.

– Нибары 9 хуҗалыкта гына терлек асрыйлар. Калганнары – өлкәннәр, яшьләр шәһәргә китә. Башлангыч мәктәпкә капиталь ремонт үткәрелсә дә, укучылар юк. Бер бала бар иде, ул хәзер Кармыш мәктәбендә белем ала. Клуб 2017 елда төзелгән. Анда бәйрәмнәр уздырыла. Кибет элек бар иде, әмма авылда аны тоту чыгымлы. Өендә бер кеше май, тоз, ипи кебек кирәк-ярак сата. «Райпо»дан автолавка сирәк кенә килә, – ди Кармыш авыл җирлеге башлыгы Илдар Фәтхетдинов.

Авыл кешеләре дә гади генә түгел. Әнә Фатыйма апа Харисова «Ана даны» медале белән бүләкләнгән, алты бала үстергән. Биш улы, бер кызы бар. Өч улы да Казан дәүләт ветеринария медицинасы институтын тәмамлаган. Илшат авылда Сабантуй оештыра. Фатыйма апа авылда үзе генә яши, балалары кайтып, хәлен белешеп тора. Мал-туар асрап гомер кичерә. Кемдер 5–6 баш терлек тота. Сөтне килеп җыялар, ди. Авылда күп кеше умарта тота, шәл бәйләүчеләр дә бар монда. Ул үзе дә оста шәл бәйләүче икән.

– Авылдашыбыз Нәфисә кирәк-яракларны саткалый. Продукцияне балалар алып кайта. Ипи булмаганда үзем пешерәм. Онны, шикәр комын китереп талар. Халык саны аз булгач, кибет тоту табышлы түгел, – ди 68 яшьлек Фатыйма апа.

Йөрмәсәң, китереп бирүче юк

Фаил Мортазин – авылның хәзрәте. Гомер буе Әлмәттә нефть өлкәсендә эшләп, 14 ел элек авылга хатыны Фәридә белән күченеп кайтканнар. Бергә яши башлауларына 50 ел икән. Ике улы – Әлмәттә, кызы Казанда яши.

– Юллар беткән, зиратны тупыл басып, карурманга әйләнгән иде. Мәчет искергән. Клуб та, һәйкәл дә юк. Авылның бетеп баруына күңел әрнеде. Әйдә, хатын, болай булмый, авылга кайтып, аны торгызыйк, дидем. Яңа йорт салдык, – дип сөйли Фаил абый, туган авылының бетеп барган елларын искә төшереп. – Мәчетне төзекләндердек. Әле менә манарасын алтыннан йөгертелгән калай белән тышлаттык. Авыл егетләре белән өч көндә туксан еллык агачларны кисеп, зиратны тәртипкә китердек. Койма кордык, анысы 465 мең сумга төште. Авылга кайтканнан бирле бер көн дә ял иткәнем юк. Авылда бар да яхшы булсын дип тырышам. Үзең йөрмәсәң, китереп бирүче юк. Бер дә булмаса, түрәләрдән хәер сорашып кайтам, Әлмәттә эшләгән хезмәттәшләрем янына ярдәм сорап барам. Әле менә зиратка керә торган юлга таш җәйгән идек, хәзер асфальт түшәр өчен район башлыгына барырга җыенам, – ди 73 яшьлек Фаил абый.

Аның әйтүенчә, җомга намазына 6–7 яшь кеше йөри, ул – иң өлкәне. Мәчет эшләп тора, уты-газына түләнә. «Авылда эш юк. Колхоз булмагач, адәм баласы шәһәргә кача. Эше, ашы булса, авыл бетми ул. Соңгы ике елда шәһәрдән 3 гаилә кайтты», – ди Фаил абый, яхшыга өметләнеп.

«Бүләкне көздән әзерли башлыйбыз»

Фаил абый кебек авыл дип тырышучылар арасында яшьләрдән Илшат Харисов та бар. Илшатның да авыл рухын сүндерәсе, яшәүчеләрне җыр-моңнан мәхрүм итәсе килми.

– Яшәүче бетеп барса да, горурланырлык яклары күп аның. Меңләгән йортлы авылларда Сабантуй уздырмыйлар, бер җырлары да юк. Ә безнең авылның биш җыры бар. Аларның барысын да танылган җырчылар башкара, – ди Илшат.

Әлеге җыр текстларын ул үзе иҗат иткән. Бәйрәмнәрдә, авылда узган концертларда яңгырый бу көйләр. Илшат бүген Чистай районындагы «Чистай» агрофирмасының сөт комплексын җитәкли. Кышын читкә эшкә китә, җәй көне авылга умарта тотарга кайта. Һөнәре буенча – зоотехник-селекционер. Нурлат, Яңа Чишмә районнарында беткән колхозларны аякка бастыруда аның өлеше зур. Күчмә тормыш белән яшәсә дә, туган авылын онытмый. Күршедәге 4 авылның таркалуы да бик нык тәэсир иткән егеткә. Менә шул авыллардан чыккан кешеләр өчен дә ул оештырган Сабантуй – үзе бер бүләк. Илшат иҗатка да вакыт таба: 2019 елда «Татар моңы» бәйгесендә катнашкан, аның җырлары белән артистлар «Татар җыры» фестивалендә «Алтын барс» ала.

– Мин нәрсәгә тотынсам да, беркайчан да мактаныр өчен эшләмим, авылга ярдәм булсын дип тырышам. Авылның халкы бик дус яши. Ватсапта авыл төркемен алып барам. Көзгә кергәч тә Авыл көне, Сабан туена бүләк алырга тотынабыз, бу эш кыш буе дәвам итә, – ди ул.

Авылда Сабан туеның күптән үткәрелгәне булмаган, озын тәнәфестән соң 2009 елда беренче тапкыр Фаил хәзрәт оештырган. Аннан бу вазыйфаны Илшат үз кулына алган.

– Ел да үткәрәбез бәйрәмне. Быел көрәштә 56 ир бил алышты. Бездә кунаклар, авылдашлар аерым көрәшә. Хатын-кызлар да ирләрдән калышмый. Әгерҗе, Чаллы, Тольяттидан килгән кызларның батыр калганы бар. Ике ел инде аларга чәшке тун бирәбез. Җиңүче егетләргә тәкә, суыткыч, телевизор ише бүләкләр әзерлибез. Авыл бәйрәменә чакырып, «Болгар» радиосына белдерү бирәбез, – ди Илшат Харисов.

Авыл көне җыр-моң таратучы гына бәйрәм түгел, аның мәгънәсе күпкә тирәнрәк. Монда мәет юучы, ләхет алучы да, авылның иң өлкән кешесе, иң зур бавырсак пешерүче дә бүләксез калмый. Әйтик, быел бавырсак пешерүдә 18 хуҗабикә катнашкан.

«... Яшәүчем син, яшәргә көч өстәүчем», – дип җырлыйлар монда. Авыл халкының берсе дә авылның бетүен, кирәксезгә әйләнүен теләми. Бар да яхшы булачак дигән зур өмет яши алар күңелендә.

– Авылга юкка гына Яшәүче дип исем кушмаганнардыр. Ничек тә булса, яшәргә тырышырга кирәк. Берсенең дә шәһәргә баласы янына китәсе килми. Саф һава сулап, тәмле чишмә суы эчеп, үз туган җиребездә рәхәтләнеп яшибез. Элек юлларда йөри торган түгел иде. Кибетче мәрхүм Канәфи абый таш салдыртты. Яшәүчебез таркалмасын, озын гомерле булсын. Бездән теләк шул, – ди авыл халкы.

Сәрия МИФТАХОВА

САБЫН ЯСАУ ОСТАЛАРЫ:

«КИБЕТТӘН САТЫП АЛГАНЫБЫЗ ЮК»

Зур Кукмара авылында яшәүче әниле-кызлы Мифтаховалар ясаган сабыннар башкаларныкыннан аерылып тора. Алар үзгә бер төрле матур, купшы. Сабыннан ясалган букетлар матурлыклары белән күз явын алса, табигый (натураль) компонентлар кушып әзерләнгәннәренең халык файдасын бик күрә икән.

Апалы-сеңелле Йолдыз белән Илүзәнең кулыннан килмәгән эш юк.

– Без тик торырга яратмыйбыз. Бисердән төрле эшләнмәләр ясау, бәйләү, алмаз белән чигү, пазллар җыю – яратып башкара торган эшләребез. Күпмедер вакыт бер эш белән шөгыльләнәбез дә, аннан туеп, икенчесе белән кызыксына башлыйбыз, – дип елмая Йолдыз.

Ул мәктәпне тәмамлап, медицина көллиятендә укый. Илүзә 8 нче класста белем ала. Сабын ясау – гаиләнең хобби. Кызларның төп ярдәмчеләре – әниләре Рузалия ханым. Аның әйтүенчә, алмаз белән чигүне дә кызларга бер шөгыль булсын әле дип башлаган булганнар.

– Бармак белән эшләү хәтердә кала, баш миенә уңай йогынты ясый. Киләчәктә үзләренә дә белеп торулары яхшы булыр, дидем. Мин кирәк-яракларны алып кайтам да, барыбыз бергә җыелып эшлибез, – дип сүзгә кушыла ул. – Зур-зур пазлларны да бик күп җыйдык. Аларын да өләшеп бетердек.

Сабын, каты хушбуй, тәнгә сөртә торган скраб, кремнар ясый торган кирәк-яракларны Казан кибетләреннән сатып алалар. Матур, купшы булсын өчен, махсус формаларның кыйммәтлесен сатып алырга тырышалар. Дөрес, Йолдыз белән Илүзә әлеге шөгыльләренә бары тик хобби буларак кына карый. Шуңа күрә көннәр буе сабын гына ясап утырмыйлар. Заказлар булганда гына эшләп бирәләр. Гадәттә, алары бәйрәмнәр алдыннан күп була. Шушы ике ел эчендә даими клиентлары да барлыкка килгән.

– Бу һич уйламаган җирдән башланган эш булды. 2019 елда Яңа ел алдыннан, бүләккә бирер өчен ясый башлаган идек. Башта ясаганнары шулай таныш-белешләргә, туганнарга таратылды. Аннан соң кызыксынып, нигезен махсус кибетләрдән ала башладык, – ди Илүзә.

Бәяләренә килгәндә, кызлар үзләре эшләгән сабыннарны 400 сумнан алып 700–800 сумга кадәр саталар. Букетларны кыйммәтрәк бәядән алучылар да бар.

Соңгы вакытта ныклап торып табигый сабын белән кызыксына башлаганнар. Анысын төрле майлар кушып ясыйлар. Технологиясе дә катлаулырак икән.

– Табигый сабыннар безгә күбрәк ошый, чөнки ул файдалырак. Сувенир сабыннар әзер нигездән (основа) ясалса, табигый төрдәгесе берничә төрле майларга (кокос, миндаль, зәйтүн) селте кушып ясала. Ягъни чын сабын килеп чыга. Соңгы елларда үзебезнең дә сабын сатып алганыбыз юк. Гел табигый сабын гына кулланабыз. Бүләккә бирергә дә матур һәм файдалы. Үзебезгә дә ясау кызык. Бер сабын икенчесенә охшамаган һәм аны берничек тә кабатлап булмый. Бер төрле рецепт белән ясаган очракта да төрле сабыннар килеп чыга. Безгә менә шунысы кызык, – ди Йолдыз.

Табигый сабынның өлгерү вакыты да озаграк. Якынча 3–4 атна кирәк. Анысының бәясе дә кыйммәтрәк. Халык шунгит, спирулина, кызыл балчык кушып ясалганын яратып ала, диләр. Бары тик кәҗә сөтеннән генә ясалганнарының да файдасын күрәләр. Аны аллергиягә каршы файдаланалар.

Шәхси архивтан

– Сабын сатып, акча эшлибез, дип әйтеп булмый. Үз бәясенә юл чыгымнарын гына өстибез. Күбрәк күңел өчен башкара торган шөгылебез бу. Бу юлы ничек килеп чыгар икән, дип кызыксынып көтеп торабыз. Бүләккә бирергә дә рәхәт, – ди кызлар.

Авырлыкларга килгәндә, Йолдыз белән Илүзә әйтүенчә, бу – бик вак һәм сабырлык сорый торган эш. Куркынычсызлык кагыйдәләрен дә үтәргә кирәк. Селте белән эшләгәндә аеруча сак булырга туры килә, ди алар. Аны кулланыр алдыннан якын-тирәдәге бөтен әйберне алып, эш урынына кеше кертмичә эшлиләр икән. Килеп чыкмаган чаклар да була. Уңышлы чыгуы кулланыла торган әйберләрнең сыйфатына да бәйле.

– Сабынны төрле рецептлар буенча ясарга була. Составына кычыткан, ромашка суы, бал, кәҗә сөте, күмер, бавыз салып ясаганыбыз бар. Моның өчен якынча ике сәгать вакыт кирәк. Бер тәүлектән соң кисеп, бер айга өлгерергә алып куялар. Кулланыр өчен дымы бетү кирәк, – дип эш тәртибе белән уртаклашты алар.

Соңгы вакытта таныш-белешләренең балаларына сабын ясау буенча мастер-класслар да уздыра башлаганнар. Каникул, туган көннәр вакытында килеп, кызларның күңелләрен күрәләр икән. Илүзә киләчәктә косметолог булырга хыяллана. Инде хәзердән үк максатына таба атлый. Аякка сөртә торган бальзам, тән өчен скраб, каты хушбуйлар ясый башлаган.

– Һәр эшне яратып башкарырга кирәк. Күңел биреп эшләгән сабыннарны халык та яратып ала, – ди әниле-кызлы Мифтаховалар.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 7405 данә
Гомуми тираж – 17243 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 345

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).
16+